УРТАК ЭШ

Ватан сакчыларына туган як көчтәнәчләрен күңел җылысына төреп озаталар

> 6–7

ПЫЧКЫ ТАВЫШЫ

Йортларга газ керсә дә, утынның һәрвакыт кирәге чыгып тора

> 16

ВИНЕРА ГАНИЕВА:

«Җитди җырларга кытлык үзен торган саен ныграк сиздерә»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 11 (29171) | Җомга | 26 гыйнвар | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Эльвира Вәлиева

КӨНЧЫГЫШКА БОРЫЛЫШ

«ВТ» ХӘБӘРЧЕСЕ МАШИНА БӘЯЛӘРЕН БЕЛЕШТЕ

Бүген илдә 44,1 миллион җиңел машина исәпләнә. Ягъни бишектәге сабыйларны, таякка таянган әби-бабайларны да кертеп, илдә яшәүче өч кешегә бер автомобиль туры килә. Узган ел гына да 1 миллионнан артык яңа машина сатылган. Бәяләре нык артуга карамастан бу. Автомобиль базары ни хәлдә? Бүген машина сату-алу, аны алмаштыру отышлымы? Яңа «тимер ат»ка ничә ел акча җыясы? «ВТ» хәбәрчесе әнә шул сорауларга җавап эзләде.

> 5

Ишетми калмагыз

Бер атна эчендә (17 гыйнвардан башлап) Казан урамнарыннан 273 мең тонна кар чыгарылган. Соңгы тәүлектә – 37,5 мең тонна. Шәһәрнең Тышкы төзекләндерү комитетында әйтүләренчә, кайбер ваемсызларның машиналарын юлда, җәмәгать транспорты өчен билгеләнгән «кеса»ларда калдырулары сәбәпле кар җыештыру эше нык катлаулана.

Казан мэры Илсур Метшин белдергәнчә, узган атнада шәһәрдә 1 миллион тоннадан артыграк кар яуган. Ул атна азагына кадәр җәмәгать транспорты юлларын тулысынча чистартып бетерергә кушты.

Узган елда Татарстанда 25219 пар өйләнешкән. Республика әлеге күрсәткеч ягыннан Идел буе федераль округында беренче урында тора.

Министрлар Кабинетының ЗАГС идарәсе мәгълүматларына караганда, Башкортстан икенче урынга чыккан. Биредә 23747 никах теркәлгән. Самара өлкәсе – өченче (19913). Иң аз өйләнешүчеләр Мордовиядә (3825 пар) һәм Мари Элда (3318) булып чыккан. Тулаем Россия буенча бер ел эчендә 947866 никах теркәлгән.

Татарстанда өйләнешкән 1 мең парга 566 аерылышу очрагы туры килә. Округта иң түбән күрсәткеч бу.

Җиңүчеләр билгеле!

«ВТ» редакциясе укучыларын һәрдаим сөендереп тора. Мәгълүм булганча, редакция, башка еллардагы кебек үк, 2024 елның I яртыеллыгына язылучылар арасында бүләкләр уйнатырга вәгъдә итте. Вәгъдә – иман. 25 гыйнварда бүләк ияләрен ачыкладык.

Бүләкләребез бу юлы да саллы иде: үтүк, мультипекарь, иттарткыч, кыска дулкынлы мич һәм тузан суырткыч. Барлыгы 957 квитанция кабул иттек. Бәхет елмайган кешеләр – кемнәр алар?

ҮТҮК – **КӘЛИМУЛЛИНА Сания**, Балтач, Арбор авылы
МУЛЬТИПЕКАРЬ – **ГАРИПОВ Ринат**, Саба
ИТТАРТКЫЧ – **ГАЛИУЛЛИНА Рәмзия**, Питрәч, Ленино-Кокушкино авылы
МИКРОДУЛКЫНЛЫ МИЧ – **ИСКӘНДӘРОВА Гүзәлия**, Мамадыш, Түбән Яке авылы
ТУЗАН СУЫРТКЫЧ – **НИГЪМӘТҖАНОВА Руфия**, Теләче, Шәдке авылы

Җиңүчеләребезне ихластан котлыйбыз! Тулырак мәгълүмат алу өчен, редакция белән элемтәгә керүегезне сорыйбыз. Бүләк ота алмаганнар боекмасын. «Ватаным»лы булу – үзе бер бүләк бит ул! Әле мондый күчтәнәчләребез күп булыр. Бездән аерылмагыз!

Районнарда ни хәлләр?

Түбән Кама

Районда быел 100 нче бала Әлфия һәм Марат Килдеевлар гаиләсендә дөньяга килде. 19 гыйнварда туган малайга Булат дип исем куштылар. Ул – гаиләдәге бишенче бала. «Һәр гаиләдә бала туу – шатлыклы вакыйга, әмма һәр гаиләдә дә биш бала тапмыйлар. Аллаһы Тәгалә ярдәмендә без моны эшләдек. Бүген улларыбыз белән кечкенә егетне каршы алырга килдек. Мин бик шат һәм борчылам да», – дип уртаклашты шатлыгын гаилә башлыгы Марат Килдеев.
(e-nkama.ru)

Чирмешән

Лашман мәктәбенә Минсәгыйть Шакиров исеме биреләчәк. «Бу тәкъдимне мәктәп коллективы, Лашманда узган җыенда катнашучыларның күпчелеге, комиссия дә хуплады. Ул моңа лаек, аның вакытында районда бик күп биналар төзелде, күләмле зур эшләр башкарылды», – диде район башлыгы Рамил Айбатов мәрхүмне искә алу мәҗлесендә. Минсәгыйть Шакиров 2023 елда 74 яшендә вафат булды. Ул 22 ел дәвамында районга җитәкчелек итте, ун елдан артык Муниципаль берәмлекләр советы рәисе булды.
(«Безнең Чирмешән»)

Ютазы

Бәйрәкә авылында яшәүче Фатыйма Фәррахова 100 яшьлек тормыш чиген узды. Бер гасырлык гомер юлы үтсә дә, юбиляр әби үзен яхшы хис итә. Дөрес, бераз начаррак ишетә, аяклары да сызлап тота, әмма кан басымы тотрыклы, башка авыруларга да бирешми. Яшьлегендә зур сынаулар аша узарга туры килгән. Дүрт абыйсы фронтка китеп, яу кырында ятып кала, 1943 елда әнисе вафат була. Сугыштан соң Фатыйма Әсгать исемле егеткә кияүгә чыга. Ире белән дүрт бала тәрбияләп үстерәләр. Кызганычка, аларның өчесе бик иртә бакыйлыкка күчә. Бүген Фатыйма Фәррахова олы улы һәм килене тәрбиясендә гомер кичерә.
(«Ютазы таңы»)

Чаллы

Шәһәр Советының XXX сессиясендә 2023 ел бюджеты үтәлеше буенча җәмәгать тыңлаулары көне расланды. Ул 6 мартта хакимиятнең 400 урынлы залында булачак. Керү ирекле. «Җәмәгать тыңлауларына килеп, һәркем бюджет үтәлеше турында хисапны тыңлый, сораулар бирә ала», – диде шәһәр мэры Наил Мәһдиев. Сессиядә шулай ук 2024, 2025–2026 елларга шәһәр бюджетына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе дә каралды. 2024 ел бюджетының керем өлеше 16 млрд 127 млн сумнан күбрәк, чыгымнары 16 млрд 157 мең сумнан артык. Аерма 2024 елның 1 гыйнварына шәһәр казнасында калган акча хисабына каплана.
(«Шәһри Чаллы»)

ИГЕЛЕК ТУЛЫ ТОРМЫШ

Сез игелек, яктылык һәм ата-ана мәхәббәте белән тулы тормыш юлын сайлагансыз! Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов республикада Гаилә елын ачуга багышланган тантаналы чарада күпбалалы гаиләләр белән очрашты. Аларга соклану һәм рәхмәт сүзләре җиткерү белән беррәттән Россия һәм Татарстанның дәүләт бүләкләрен тапшырды.

Татарстанда илдә игълан ителгән Гаилә елын ачу тантанасы Казан Кремлендә узды. Рөстәм Миңнеханов сүзләре белән әйтсәк, гаилә – күпмилләтле дәүләтебезнең нигезе, ышанычлы тыл һәм һәркем өчен таяныч ул.

– Гаилә безгә авыр минутларда көч бирә, үз-үзебезгә ышанырга өйрәтә, буыннар чылбырын өзми саклый. Һәр гаиләнең тигезлектә, татулыкта һәм рәхәт тормышта яшәве, киләчәккә ышаныч белән каравы бик мөһим, – диде ул.

Безнең республикада күпбалалы, тәрбиягә бала алып үстерүче гаиләләр, хезмәт һәм фән династияләре – дистәләрчә мең күркәм гаилә яши. Алар – Татарстан горурлыгы.

– Сез игелек, яктылык һәм ата-ана мәхәббәте белән тулы тормыш юлын сайлагансыз. Сезгә соклануымны һәм хөрмәтемне белдерәм! – диде Татарстан Рәисе, чарада катнашкан гаиләләргә рәхмәтен белдереп.

tatarstan.ru

6 ул һәм 4 кыз үстергән Наилә ханым Галиева Россиядә «Герой ана» исеменә лаек булган хатын-кызларның берсе. Ә Татарстанның яңа тарихында бу исемне ул беренче булып алды.

Рөстәм Миңнеханов тантаналы чарада унбер гаиләгә дәүләт бүләкләре тапшырды. 10 бала әнисе **Наилә Галиева** (Балтач районы) – «Герой ана» исеме һәм ордены; 7 бала әти-әнисе **Динара һәм Андрей Косачлар** (Казан) – «Ата-ана даны» ордены; 5 бала әти-әнисе **Светлана һәм Андрей Гранковскийлар** (Казан), 4 бала әти-әнисе **Гөлнур һәм Илдар Рәфыйковлар** (Казан), 5 бала әти-әнисе **Чулпан һәм Иршат Хәнифовлар** (Аксубай) – «Ата-ана даны» ордены медале, 11 бала әти-әнисе **Ирина һәм Денис Федоровлар** (Әлмәт районы), 8 бала әнисе **Исламия Ибраһимова** (Казан) «Ата-ана батырлыгы» медале белән бүләкләнде. Шулай ук 5 бала әнисе **Алия Ибраһимова** (Саба районы), 5 бала әнисе **Лилия Сафиуллина** (Казан, Россия Герое Айнур Сафиуллинның әнисе), 5 бала әнисе **Руфина Шәйгарданова** (Бөгелмә) һәм 5 бала әнисе **Раушания Закирова** (Арча районы) «Ана даны» медале белән бүләкләнде.

МӘХӘББӘТ УЧАГЫ

23 гыйнвар кичендә Мәскәүдә Россиядә игълан ителгән Гаилә елын ачу уңаеннан тантана узды. Әлеге зур чарада катнашкан гаиләләр арасында тумышлары белән Балтачтан булган Сөмбел һәм Самат Зыятдиновлар да бар иде. Алар башкалада кабынган «Гаилә учагы»н Татарстанга да алып кайтты.

Хәтерләсәгез, Зыятдиновлар никахларын да нәкъ менә Мәскәүдә, «Россия» күргәзмә-форумында рәсмиләштергән иде. Зыятдиновларның милли туйлары декабрь башында Татарстан Республикасы көненең иң матур өлеше булды. Гаилә елын ачу тантанасы да «Россия» форумы кысасында узды.

Тантаналы чарада сәхнәдә басып тору бәхете дә елмайган аларга. Бөтен Идел буе федераль округыннан нәкъ менә безнекеләрне – Зыятдиновларны сайлап алганнар.

tatar-inform.ru

Нәкъ менә әлеге учак 2024 елның символы булачак.

– Без сәхнәдә Татарстан гына түгел, Идел буе федераль округы исеменнән басып тордык. Сәхнәгә һәр округтан берәр гаилә чакырылган иде. Алар арасында басып тору безнең өчен икеләтә җаваплылык һәм горурлык булды, – ди Сөмбел.

Бар ил каршында «Гаилә учагы»н кабызу Зыятдиновлар тормышындагы иң дулкынландыргыч һәм гомергә истә кала торган мизгел булыр, мөгаен. Үзләре дә шулай ди.

– Әлеге учакны Кырымда 40 ел бергә гомер итүче матур гаилә кабызды. Шуннан аны башка округларга, шул исәптән, безнең лампадага күчерделәр, – дип сөйләде безгә Самат. – Утны кулдан төшермәдек, Казанга сүндермичә алып кайтып тапшырдык. Шөкер, өстебездә булган җаваплы вазыйфаны үтәдек.

Очкычтан төшүгә, алар әлеге учакны яңа гына гаилә корган яшь парга тапшырды. Ул учак «Казан» гаилә үзәгендә сакланачак.

– Яшь парлар аның ялкыныннан үз гаилә учакларын кабыза алачак, – диде бу хакта Татарстан Министрлар Кабинетының ЗАГС идарәсе башлыгы Гөлшат Нигъмәтуллина.

Самат белән Сөмбел алып кайткан утны Идел буе федераль округының башка төбәкләренә дә тапшырдылар.

ЧИР ГЕНӘ ТҮГЕЛ

Республикада гомер озынлыгы арта, дәвалау оешмалары яңартыла, моңарчы күрелмәгән катлаулы уникаль операцияләр ясала... Шулар белән беррәттән авырткан урыннар да бар. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының узган елгы эш йомгакларына багышланган коллегия утырышында шул хакта сөйләштеләр. Утырышта Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Гомер озынлыгы

Узган ел Татарстанда үлем-китем очраклары 4,5 процентка кимегән. Соңгы тапкыр мондый күрсәткеч 1990 нчы елларда теркәлгән булган. 2023 елда республикада уртача гомер озынлыгы 75,4 ел тәшкил иткән. Быел аны 75,57гә җиткермәкчеләр.

– Үлем-китем очракларының күпчелеге элеккечә үк йөрәк-кан тамырлары авырулары аркасында (47 процент) килеп чыккан. Икенче урында – яман шеш (16,5 процент). Узган ел теркәлгән үлемнәрнең 8 проценты исә тышкы сәбәпләр аркасында килеп чыккан, – дип ачыклык кертте Марсель Миңнуллин.

Бер ел эчендә эш яшендәге кешеләр арасында үлем очраклары 1,2 процентка арткан. Иң зур саннар – Яңа Чишмә, Спас һәм Югары Ослан районнарында. Министр әлеге район хастаханәләре җитәкчеләренә кисәтү ясады. Вазгыять үзгәрмәгән очракта эштән алу белән дә янады.

Балалар сәламәтлеге

Марсель Миңнуллин сүзләренә караганда, Татарстанда яңа туган сабыйлар арасында үлү очраклары кими бара. Узган ел республикада 1 мең балага 3,1 үлем очрагы туры килгән. Аннан алдагы ел белән чагыштырганда, бу 6,1 процентка азрак.

– Республиканың 13 районында балалар арасында үлүчеләр бөтенләй юк. Ә менә Әлмәт районында узган ел барлыгы 9 (!) баланың гомере өзелгән. Районның бала тудыру йортына сораулар күп. Тукай һәм Лениногорск районнарында да яңа туган сабыйлар арасында үлем очраклары аеруча күп теркәлгән, – дип белдерде министр.

Марсель Миңнуллин фикеренчә, хәвефле саннарга Казанда күппрофильле балалар стационары булмау да йогынты ясый. Бүген төп авырлык ДРКБ табиблары җилкәсенә төшә. Табиблар көн саен 400ләп кеше кабул итә. Соңгы ун елда аларның эше өч тапкыр арткан. Министр, форсаттан файдаланып, Рөстәм Миңнехановтан балалар өчен яңа дәвалау оешмасы булдыруга ярдәм дә сорады.

Россия сәламәтлек саклау министры ярдәмчесе Ольга Гусева әниләр арасында үлем-китем очракларын кисәтүгә дә зур игътибар бирергә өндәде. Ник дигәндә, узган елның декабре белән быелның гыйнвары аралыгында республикада бала тапкан өч ананың гомере өзелгән.

Татарстан Рәисе Рөстәм МИҢНЕХАНОВ:
– Без төп демографик күрсәткечләр буенча уңай үзгәрешләр күрәбез. Узган ел сәламәтлек саклауны үстерүгә 119 млрд сум акча бүлеп бирелде. Шуларның 14 млрд сумнан артыгы төзелешкә һәм капиталь ремонтка исәпләнгән иде. Сәнәгать оешмаларында диспансеризация уздыру, сәламәтлек саклау тармагының беренчел звеносын яңарту эшен дәвам иттерергә кирәк. Табибка языла алмаудан зарланучылар күп. Мондый зарларның күбесе Түбән Кама, Чистай, Чаллы һәм Казанда яшәүчеләрдән килә. Менделеевск, Нурлат, Баулы, Мамадыш районнарында, Чаллыда исә күрсәтелгән медицина ярдәме сыйфатыннан канәгать булмаучылар шактый. Россия Федерациясе Президенты Указы белән 2024 ел Гаилә елы дип игълан ителде. Ул, беренче чиратта, демографик хәлне яхшыртуга һәм милләтнең сәламәтлеген ныгытуга юнәлдерелгән. Хәрби хәрәкәтләр зонасыннан кайткан егетләргә медицина ярдәме күрсәтү дә игътибар үзәгендә тора. Россия Оборона министрлыгы белән бергә без яралыларны каршы алабыз һәм аларга кирәкле ярдәм күрсәтәбез.

МХОда катнашучыларга ярдәм

Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә төп ярдәм Казан һәм Чаллы шәһәрләрендәге ветераннар госпиталендә күрсәтелә.

– Республика клиник хастаханәсендә махсус хәрби операциядә катнашучыларны дәвалау өчен 300 ятак урынлы бүлек эшли. Республиканың дәвалау оешмаларында егетләргә һәм аларның гаиләләренә өстенлек бирелә, – диде министр.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сан түгел, сыйфат булсын

Татарстанның Мәдәният министрлыгы еллык коллегиядә узган елга йомгак ясады һәм яңасына бурычларны билгеләде.

Мәдәниятле саннар

Мәдәният министры Ирада Әюпова сүзләренә караганда, узган ел республиканың мәдәният оешмалары 2,6 млрд сум акча эшләгән. Бер елда керем 1,5 млрд сумга диярлек арткан. Муниципаль мәдәният оешмаларының керем күләме – 800 млн сум. Бу узган ел белән чагыштырганда 42 процентка диярлек күбрәк.

Ә узган елның иң табышлы мәдәният объекты дип Казан циркы табылган. Оешма бюджеттан тыш керемнәр буенча инде икенче ел рәттән беренче урынны били. Икенче урында – Зөя утрау-шәһәрчеге музей-тыюлыгы, өченче – Камал театры. Шулай ук, былтыр авыл җирлекләрендә 27 мәдәни-ял итү урыннары төзелгән, 5 музей техник яктан җиһазландырылган. 15 мәдәни-ял итү оешмасына капиталь ремонт үткәрелгән.

Сабан туйлары

Узган ел Татарстан Россия төбәкләрендә һәм чит илләрдә 364 Сабан туе үткәргән. Быел милли бәйрәмебезне азрак оештырып, санын киметергә булганнар. Республика барлыгы 339 Сабан туе үткәрергә ниятли.

– Алдыбызда узган ел Рөстәм Миңнеханов куйган бурыч та тора. Сабан туйларын оештыруда эчтәлек мәсьәләсе актуаль булып кала. Шуңа күрә барыгызның да бу мәсьәләне контрольдә тотуын сорыйм. Традицияләребезнең кыйммәтен югалтмыйк, – дип искәртте Әюпова.

Пушкин картасы

Республикада 318 меңнән артык кешенең Пушкин картасы бар.

Сатылган билетлар саны, керем буенча республика лидерлар рәтендә, Россия төбәкләре арасында дүртенче урында тора. 2023 елда 451 миллион сумлык билет сатылган. Әмма безнең төбәк өчен бирелгән ресурсларның 35 проценты гына файдаланылган.

Мәдәни башкала

Республикада «Татарстанның мәдәни башкаласы» бәйгесен ел саен үткәрергә ниятлиләр. Яңалыклар моның белән генә бетми: җиңүче районга быел 1 миллион сум биреләчәк.

– Узган ел бу бәйге иң зур һәм иң кирәкле фестивальләрнең берсе булды. Рәис кушуы буенча быел без бу традицияне дәвам иттерәчәкбез. Хәзер аның графигы төзелә, катнашучылар һәм җиңүчеләр өчен бонуслар тагын да күбрәк булачак, – диде Ирада Әюпова.

Спектакльләр цифрлаша

Татарстан театрларына исә мәдәният министры 1 апрельгә кадәр репертуарларындагы спектакльләрне цифрлы форматка – видеоязмаларга күчерергә кушты. Якын арада драма әсәрләрен сатып алу процедурасы үзгәртеләчәге турында да игълан итте. Репертуар сәясәтенә аерым игътибар биреләчәк. Матурлыгыннан бигрәк, эчтәлеге кирәк бүгенге заманда.

Ләйсән САФИНА

Тынычлык хакы

Эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең һөнәри осталыгы, хезмәт сөючәнлеге һәм фидакарьлеге нәтиҗәсендә Татарстанда җинаятьчелеккә бәйле вазгыять тотрыклы. Бу хакта Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының еллык коллегия утырышында әйтте.

Чарада Россия тышкы эшләр министры урынбасары – статс-сәркатип Игорь Зубов, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин да катнашты. Былтыр республикада 55444 җинаять теркәлгән. Шуларның 17 меңнән артыгы авыр һәм аеруча авыр җинаятьләргә туры килгән. Хокук саклау органнары хезмәткәрләре 24 меңгә якын җинаятьчел һөҗүмне ачыклаган. Ел дәвамында оешкан җинаятьчел төркемнәрдә катнашкан 697 кеше җинаять җаваплылыгына тартылган. ФСБ һәм прокуратура белән берлектә террорчылыкка бәйле – 58, экстремистик юнәлештәге 24 җинаять ачыкланган. Моңа кадәр кузгатылган 42 җинаять эше буенча гаепләү карарлары чыгарылган, 37 кеше җинаять җаваплылыгына тартылган.

2023 елда Татарстанда, мәгълүмати технологияләрне кулланып, 18 меңгә якын җинаять кылынган. Шул исәптән, 13,3 меңе – мошенниклык, 4,5 меңе – банк счетыннан акча урлау, 4 меңгә якыны законсыз рәвештә наркотик сату яки таратуга туры килгән. Читтән торып урлау һәм мошенниклык очракларын тикшерү буенча республика ил күләмендә бишенче урында тора.

Узган ел икътисадый юнәлештәге 2,6 мең җинаять ачыкланган. Алар буенча 3,9 миллиард сумлык матди зыянны каплау тәэмин ителгән. 8 финанс пирамидасы эше туктатылган, аларның эшчәнлегеннән 2 меңнән артык кеше зыян күргән.

Рөстәм Миңнеханов үз чыгышында билгеләп үткәнчә, Татарстан – даими үсеш юлында. Бу – республика икътисадының төп тармакларының җайга салынган эше, башкарма хакимият органнарының һәм хокук саклау структураларының тыгыз хезмәттәшлеге нәтиҗәсе. Татарстан Рәисе быел республикада җитди сәяси һәм спорт чаралары узачагына да игътибар итте.

– Әлеге чараларны уңышлы итеп уздыру иң беренче чиратта хокук саклау органнары тарафыннан зур әзерлек эшен таләп итә, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан Рәисе министрлык эшчәнлегенең мөһим юнәлешләренең берсе дип экстремизм, милли һәм расаара түземсезлек уятуга каршы торуны атады. Балигъ булмаганнар арасында җинаятьчелеккә каршы көрәшнең әһәмиятен билгеләп үтте. Мәгълүмати технологияләрне кулланып кылынган җинаятьләр саны арту турында сөйләгәндә, гади халык арасында даими аңлату эшләре үткәрергә кирәклеген ассызыклады. Бу эштә, шул исәптән, «Татмедиа» республика агентлыгына зур өметләр багланунын әйтте.

Бүген наркотикларның законсыз әйләнешенә, коррупциягә каршы көрәш, икътисадый иминлек кебек юнәлешләр дә игътибар үзәгендә, дип билгеләп үтте Рөстәм Миңнеханов. Ул миграция мәсьәләсенә дә аерым тукталды.

– Без үз тәкъдимнәребезне әзерләдек һәм аларны ил Хөкүмәтенә юлладык. Мигрантлардан баш тарта алмыйбыз, алар белән эшләргә, тиешле шартлар тудырырга кирәк, – диде Татарстан Рәисе.

Әйтеп кенә бактым

Җитеп бетми бугай

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

Дөнья бертөрле генә бармый. Тормыш та, табигать тә кырыкка төрләнә. Мондый хәлләр бераз кәефне кыра үзе, тик бирешмәскә тырышам. Сөйләсәм, җүләр диярсез инде, мин иң күңелсез хәлләрдән дә файда алырга омтылам, шуның белән күңел юатам. Хәтта елмаеп та азапланам.

Соңгы көннәрдә ишеп-ишеп кар яуды һәм халык моны: «Быел кыш бик начар килде», – дип бәяләп тә өлгерде. Шул ук вакытта: «Шөкер, быел уңыш әйбәт булачак», – диючеләр дә булды. Болары – минем ише «җүләр»ләр инде. Мин тормышта төрле күңелсезлекләр, табигать бәла-казалары килеп чыга торсын димим. Әгәр чыга икән, алар безгә сынау итеп җибәрелгән, дим. Шул сынауларны уза алсак, тагын да чыныгырбыз, яшәү дә кызыграк булыр дип әйтү инде.

1987 елны җиденче гыйнвар көнне яңгыр яуды, икенче көнне буран чыкты, суытып җибәрде, бозлавыкны кар каплады. Актанышка, атаклы «Агыйдел» җыр һәм бию ансамбле турында Үзәк телевидение өчен тапшыру эшләргә килгән көннәр бу. Ходайның рәхмәте, Актаныш уртасында таеп егылып, аяк сындырдым. Ах-ух килеп сызланып ятмадым.

Соңрак, ярый әле аяк сындырдым, дип куандым да. Ни өчен? Хәзер әйтәм. Радио-телевидениенең Зеленый Бордагы ял базасында култык таякларына таянып, ылыс исләрен иснәп йөргәндә, мине «Гостелерадио» компаниясе җитәкчесе Илгиз Хәйруллин күреп алды. Яныма килде дә: «Казанга кайткач, миңа кереп чыгарсың әле», – диде. Казанга шул ук көнне кайтып киттем һәм иртәгесен иртүк җитәкченең ишек төбенә килеп бастым. Бүлмәсенә алып керде бу, шуннан соң: «Риман, инвалид кешене болай йөртеп булмас, дип уйлаштык та сиңа фатир бирергә булдык», – димәсенме?! Ике култык таягын канат итеп дигәндәй, коммуналь фатирыма очып кайтып кердем. Ул көнне шатлыктан күзгә йокы кермәде. Хатыныма: «Ярый әле аяк сындырдым», – дидем. Ә ул: «Сиңа бераз җитеп бетми бугай», – дип, аркадан сөйде.

2010 елны Тукай эзләреннән Казахстанга, Кытайга сәфәр чыктык. Кире кайтканда Карагандага 90 чакрым кала күпердән очып, комлыкка барып төштек тә, сигез мәртәбә әйләндек. Машинаның карар җире дә юк, ә без – мин һәм тагын өч журналист кыз исән калдык. Моңа ничек шатланмыйсың инде, җүләр! Әле күпернең икенче ягына очкан булсак, суда тончыгып үлә идек. Комлыкка барып төшүгә дә куанып бетә алмадык.

Бер елны фатир балконыннан артка чигенеп чыгып килгәндә, кечкенә уенчык тупка басып егылдым. Шул туп шикелле тәгәрәп кенә киттем инде, малай! Бүлнискә алып бардылар, табиб: «Бот сөягегез бик матур итеп сынган, чәрдәкләнмәгән. Үз сөякләрегез бик әйбәт, бүтән егылмагыз, юкса тимер белән ялгыштырырга туры киләчәк», – диде. Куркытуына исем китмәде, ә менә «сөякләрең әйбәт» дигән сүзләренә ничек шатлануларымны белсәгез! Дуслар алдында, сөягем әйбәт, дип мактанып та йөрдем әле. Һәрнәрсәдән, хәтта күңелсезлекләрдән дә берәр яхшылык табарга тырышып яшәүгә җитми инде ул. Мондый уйлар күңелгә яши-яши керәдер, дим. Тик шул ук вакытта кешегә яши-яши «меқ-меқ» картка әйләнү куркынычы да яный. Ә мин хәлемне сорашсалар, һәрвакыт: «Әйбәт бит!» – дип җавап бирәм, әле кайчак: «Кайгыларга баш имә, кайгыларга башың исән, рәхәт яшәрмен димә...» – дип җырлап да куям. Һәм, шөкер: «Риманга җитеп бетми, ахрысы», – дигән сүз ишеткәнем юк. Ә сезнең хәлләр ничек соң?

ЯШӘҮНЕҢ ХАСИЯТЕ

Рәшит
ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

Моннан егерме еллар тирәсе элек бу темага тулы бер язмалар циклы биргән идем. «Мәгърифәт» дигән газета бар иде, шунда ел дәвамында даими рәвештә шул хакта гына яздым. Тема исә беренче карашка бик гади: яшәүнең мәгънәсе. Соңгы язманы декабрьдә өлгерттем ул чакта. Хәтерлим: газетаның ул саны кулдан-кулга йөрде. «Мәгърифәт»не яздырып укымаучылар да, язманы тотып, янга килгәләделәр. Эш шунда: мәгънәсе юк дип саналган нәрсәләрне без ташлыйбыз, шуңа күрә яшәү мәгънәсе – асылда дулкынландырырга тиеш тема ул. Әйтик, кесәгә таш тутырып йөрү – мәгънәсезлек, шуңа күрә шаяртып кемдер кесәгә таш тутырып куйса, аны шундук бушатабыз.

Кигән кием белән дә нәкъ шулай: яңа булганда, таушалмаганда аны яратып киябез, чөнки безне күркәм итеп күрсәтә, кайчак вакытлы гына булса да абруй һәм дәрәҗә дә өсти. Аның мәгънәсе шунда. Хуҗа Насретдин тикмәгә генә: «Аша, кием, аша, кием», – дип әйтмәгән. Әмма тузуга, кием ташлана. Ләкин бар бит шундый җыр: безнең халык: «Кигән кием ничек туза, яшь гомер шулай уза», – дип җырлый. Күрәсең, бик борынгы җырдыр, чөнки Галимҗан Ибраһимов үткән гасыр башында ук аны үзенең «Сөю-сәгадәт» исемле хикәясендә китерә. Кеше гомере никадәр генә озын булмасын, тиз үтә. Гомер азагында шактый катлаулы һәм катмарлы юл узгач: «Бу мәшәкатьләр нәрсә өчен кирәк булды?» – дигән сорау туса, бер дә гаҗәп түгел. Кайвакыт андый провокацияле сорау яшь чакта ук туа да адәм баласы юлны дәвам итүдән мәгънә тапмый. Балалар һәм яшьләр арасында суицидлар статистикасын гына карагыз.

Болай үзе Җир йөзендә мәгънәсе булмаган берни дә юк. Хәтта кәя күбәләге дә максат белән яратылган: ул безгә, кешеләргә хезмәт итә. Кешеләрнең күпчелеге аның хезмәтен, ягъни мәгънәсен аңламый. Әмма шул корткыч бөҗәкнең дә зур кыйммәте бар.

Адәм баласы исә кәя күбәләге генә түгел, аның яшәвенең мәгънәсе, максаты билгеләнгән. Ләкин кешеләр, аңламыйча, тормышта ялгыш максатлар куя, яшәүнең мәгънәсен хаталы аңлый. Бүгенге җәмгыятьтә эпидемия төсен алган депрессия һәм психоз – шуның нәтиҗәсе. Яшәүнең мәгънәсен матди байлыкларда күргән адәм баласы үзе теләгән муллыкка ирешә алмаса, стресс кичерә, ирешкән очракта бәхет тойгысы бик кыска гомерле була. Максатны югалтмыйм дип, кеше яңа биеклек билгеләп, шуны яулау өчен көрәшә башлый, бу көрәштә бер киртәне дә санга сукмый, тыелган адымнарны да җиңел атлый. Ришвәтчеләр һәм коррупционерлар статистикасына күз салыгыз. Тонналаган алтын-көмеш һәм кәгазь акча туплана, әмма нәфес барыбер туймый. Максатка омтылыш шулкадәр көчле була: хәтта үлем җәзасы ихтималлыгы да куркытмый. Кытай, мәсәлән, коррупционерлар белән бик кырыс көрәшә, ике дә уйламый, аларны теге дөньяга озаталар. Шуңа карамастан үткән көздә генә анда оборона министрыннан башлап ракета гаскәрләрен җитәкләгән барлык генераллар кулга алынды, чөнки хәрби бюджетны үз максатларында файдаланганнар. Хәзер инде тупланган акча аларга бер тиенлек тә файда китермәячәк.

Яшәү мәгънәсен данда, дәрәҗәдә, карьерада күрүчеләр дә кайчан да булса үзләрен кулларында ватык уенчык тоткан бала хәлендә тоялар. Дан кайчан булса да бер онытыла, карьера баскычы җимерелә, яисә аның иң югары басмасында утырганда кисәк кенә гомер төгәлләнә.

Дөнья малы, эш урыны, балалар, гомумән, бу дөньяның барлык ләззәтләре – болар барысы да яшәвебезнең чаралары гына. Алар безнең тереклегебезне тәэмин итү мәгънәсенә генә ия. Чараны максатка әйләндерү – депрессиягә китерә торган нәрсә. Әйтик, юлга кузгалганда, безнең максатыбыз машинага утыру түгел бит инде. Казанга, яисә башка бер шәһәргә барырга чыкканда, без бөтенләй башка максатларга омтылабыз, машинаны шул максатка бару чарасы итеп кенә файдаланабыз. Максатка ирешү белән, безнең чит җирләрдә калуыбызның мәгънәсе бетә һәм кире даими яшәү урынына әйләнеп кайтабыз.

vk.com

«Әйләнеп кайтабыз» дигән сүзне ассызыклыйк әле. Асылда бу дөнья да безнең даими яшәү урыныбыз түгел. Күпме генә яшәмә, барыбер китәргә туры киләчәк. Үлем хәбәрен ишеткәч, без, мөселманнар: «Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун», – дибез. «Раҗигун» сүзе гарәпчәдән тәрҗемә иткәч, «кайтабыз» дигән мәгънә бирә. Бик зур юату һәм нәсыйхәт потенциалы бар ул сүздә, яшәүнең мәгънәсен шул билгеле дә инде. Даими яшәү урынына без бары тик бер йөк – «гамәл» дигән багаж төяп кенә китәбез. Миллиардлаган доллардар кала, сөйгән ярның (яисә ярларның) чибәрлеге әһәмиятен югалта. Үлем түшәгендә ятканда, хакимлек иясе булу да шатлык бирми. Бу дөньяда яшәгәндә үк тираннарның да тәхете бик тотрыксыз. 2011 елның җәендә Каддафи Триполидагы Яшел мәйданда үзен данлаган миллион кешелек митинг җыйган иде. Ике айлап вакыт узуга, шул кешеләр аның үлемен тантана итеп, мәете янында фотога төшәләр.

Америка язучысы Пол Виллардның «Иске телефон» исемле кыска гына, әмма бик популяр бер хикәясе бар. Аның сюжеты шундый: кече яшьтәге бала әти-әнисенең, телефоннан белешмәләр бюросына шалтыратып, үзләренә кирәкле мәгълүмат алуын күреп яши. Һәм көннәрдән бер көнне өйдә беркем дә югында бармагына чүкеч белән суга да шул бюро операторына мөрәҗәгать итә. Оператор бала белән бик теләп сөйләшә, яратып киңәш бирә. Мондый сөйләшүләр даимигә әверелә, чөнки таныш булмаган ике йөрәк бер-берсен аңлый. Көннәрдән бер көнне бала читлектәге кенәрие үлгәч тә, кайгысын әйтеп, телефоннан шалтырата. «Пол, – ди аңа оператор, – исеңдә тот: сайрый торган башка дөньялар да бар». Хикәянең укучыны үзенә тарта торган рациональ орлыгы һәм «изюминка»сы да шул җөмләдә яшеренгән. Шуңа күрә ул әсәр ахырында тагын бер кабатлана. Безнең тормышның да мәгънәсе шунда: башка дөньяга үзебез белән ни алып китүебездә.

Эльвира ВӘЛИЕВА

КӨНЧЫГЫШКА БОРЫЛЫШ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Ач капкаңны, «Ли» килә!

Башкаланың Салмачы бистәсендә яшәүче Рөстәм Кәлимуллин быелтыр яңа «Нива» машинасы сатып алган.

– Үз йортыбыз белән яши башлагач, зуррак машина аласы килде, – дип сөйли ул. – Теләсә нинди юлдан узарлык «иномарка»лар бик кыйммәт, шуңа күрә гаиләм белән уйлаштык та якынча 1 миллион сумга «Нива» сатып алдык. Быелгы буранда шуңа сөенеп туя алмыйм. Бер тапкыр да батып калмадым. Машина куярга урын эзләп аптырыйсы да юк. Кар көртендә үк калдырып китәм. Үзебездә чыккан машина безнең юллар өчен иң яхшысы.

«Автостат» агентлыгы мәгълүматларына караганда, бүген илдәге машиналарның 67 проценты чит илнеке. Ә менә аерым модельләргә бүлеп карасак, «Лада» автомобильләре күбрәк. Ил буенча үзебездә җитештерелгән 12 миллионнан артык машина чаба. Икенче урында – «Тойота» (3,8 миллион). «Киа» исә – өченче (2,6 миллион). Беренче бишлеккә «Хундай» (2,3 миллион) һәм «Рено» (2,1 миллион) да эләккән.

Хәер, вазгыять якын арада ук үзгәрәчәк, ди белгечләр. Ник дисәң, соңгы бер ел – ел ярым вакыт эчендә автомобиль базарын Кытай машиналары басып алды. 2022 ел нәтиҗәләре буенча ил автопаркының 40 проценты үзебездә җитештерелгән машиналарга туры килсә, быелтыр әлеге күрсәткеч 30 процентка гына калган әнә. Безнекеләрне кем кысрыклавын кычкырып әйтмик, болай да аңлашыла бит. Россия автомобиль дилерлары ассоциациясе мәгълүматларына караганда, быелтыр Кытайдан безгә рәсми рәвештә 19 яңа автомобиль бренды кергән. Күз күргән, колак ишеткән «Чери», «Джели», «Хавейл», «Танк» кебек модельләргә «Каи», «Баик», «Ли», «Хаима», «Айто» кебек яңа атамалар да өстәлгән. Алай гына да түгел, быел бездәге Кытай автомобиль брендлары 40–45кә җитәчәк, дип фаразлана. Тәкъдим сораудан артып китеп, машина бәяләре төшә башларга мөмкин, дип өметләнүчеләр дә бар. Тик, Мәһдиев әйтмешли, едва ли.

«Укытучы түгелме?»

Машина бәяләрен «ВТ» хәбәрчесе дә белеште.

– Быелтыр күпмедер вакыт сатылмыйча торганнан соң, кабат пәйда булгач, «Лада Веста» автомобиленә сорау зур, – ди автосалонда машина сатучы Марсель. – Кайбер детальләре, запас частьлары чит илнеке булгач, ул күпмедер вакыт җитештерелмичә торды. Хәзер «Веста»ның стандарт комплекты 1 миллион 589 мең сумнан башлана. Нигездә ак яки кара төстәге машинаны сайлыйлар. Андыйлар җитәрлек. Ә менә көмеш төсендәгесен бераз көтәргә туры киләчәк. Ничек кенә булмасын, арзанлы машиналар арасында «Веста» иң отышлысы. Круиз-контроле (тизлекне үзе көйләүче система. – **Ред.**) дә бар хәтта. Өстәмә җиһаз һәм уңайлыклары булмаган «Гранта» 847 мең сум тора. Салоннан чыкканчы, ул да 1 миллион сумга баса инде.

«Веста»ны кредитка исәпләп тә күрсәттеләр. Алдан 500 мең сум түләгән очракта, җиде елга кредит аласыз икән, ай саен 33 мең сум акча түлисе. Кредит ставкасы – 18 процент. Тик банклар мондый түбән процент белән бурычка акча бирергә ашыкмый. Күпчелек кредит оешмаларында ул 20–25 процент тәшкил итә.

– Сезнең гаиләдә махсус хәрби операциядә катнашучы, укытучы яки табиб юкмы? Алар ташламалы кредиттан файдалана ала, – дип тә юатырга тырышты Марсель.

freepik.com

Яңа машинага ничә ел акча җыярга кирәк икәне билгеле. Татарстанстат мәгълүматларына караганда, Татарстанда гыйнвар аенда уртача хезмәт хакы 46 мең сум тәшкил иткән. Әйтик, айлык акчаның өчтән берен җыеп барабыз, ди. Бу очракта бер кешегә «Гранта» өчен – 5 елга якын, «Хавейл Джолион»га – 12 еллап акча тупларга кирәк булачак. Соңгы сораштырудан күренгәнчә, илдә яшәүчеләрнең 8 процентының гына кулында машина сатып алырлык акчасы бар.

Билгеле булганча, ташламалы автокредит табибларга, укытучыларга, инвалидларга, махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына бирелә. Дәүләт машина бәясенең 20 проценты күләмендә ташлама бирә. Федераль программада үзебездә җитештерелгән автомобильләр, «Хавейл Джолион» һәм «Москвич 3» катнаша.

КИҢ ТАРАЛГАН МАШИНА МОДЕЛЬЛӘРЕ КҮПМЕ ТОРА?

(млн сумнан)

«Лада Нива»	1,1
«Лада Ларгус»	1,9
«Хавейл Джолион»	2,1
«Чери Тигго 7 Про»	2,3
«Киа Соул»	2,5
«Хавейл F7»	2,6

Иске яңадан саклый

Машина бәяләре кыйммәт, шуңа күрә рульдә йөрергә теләүчеләр, ничарадан бичара дигәндәй, кулланышта булганнарына да еш утыра, ди автомобильләр сату белән шөгыльләнүче Зөлфәт Галимов.

– Якынча алсак, яңа һәм иске машина сатып алучыларның нисбәте иллегә – илледер, – ди ул. – Сер түгел, халыкның акча ягы кысынкы. Ә кулланышта булган машиналар арзанрак. Статистика мәгълүматларыннан күренгәнчә, бүген аларның уртача бәясе 1,3 миллион сум тора. Яңалары арасында «Лада» автомобильләре иң арзаны булгач, иң беренче чиратта, шуларны тәкъдим итәбез. Алардан соң – Кытай машиналары. Аларның төрлесе бар: 1,5 миллион сумга да, 7 миллион сумга да сатып алырга мөмкин.

Зөлфәт Галимов әйтүенчә, яңа машина сатып алу отышлырак.

– Тик мәсьәләнең икенче ягы бар: рульдә йөрүчеләр машиналарын алмаштырырга ашыкмый. Чөнки бүгенге шартларда кулда булганын ычкындырып, аннан да яхшырагын табу шикле. Булганы йөреп торсын, диләр. Шуңа күрә кулланышта булган машиналар базарында нигездә 8–10 ел элек чыккан автомобильләр сатыла. Дөрес, параллель импорт буенча безгә кулланышта булган яңарак автомобильләр дә кайта. Тик аларга дәүләт гарантиясе юк, – ди эшкуар.

Машина Кытайда җитештерелгән икән, димәк, сыйфатсыз дигән сүзләр белән дә килешми ул.

– Бу – бездә электән калган фикер. Кытай автомобильләренең төрлесе бар. Башка брендлар арасында да шул ук хәл. Мәсәлән, «Гранта» һәм «Веста»ның сыйфатын чагыштырып карагыз. Кытай җитештерүчеләре бик акыллы эшләде: алар Европа машина заводларын сатып алып, үз эшен шунда дәвам иттерде. Мәсәлән, «Джели» машинасы «Вольво» базасында җыела. «Ли»ның эче, гомумән дә, «Роллс Ройс»ныкы. Элек тә «Мерседес», «Тойота»лар ватылмыйча тормаган. Кытай машиналарын начар дип санамыйм. Хәтерләсәгез, үз вакытында Корея автомобильләренә дә бик шикләнеп карый идек, – ди Зөлфәт Галимов.

Фикер

Илдус САФИУЛЛИН, икътисад белгече:

– Якын арада автомобильләргә бәя төшмәячәк. Ә менә яздан соң кыйммәтләнүе бик мөмкин. Рәсми саннардан күренгәнчә, быелтыр Кытай автомобильләре – 30, ә үзебездә җитештерелгәннәре 40 процентка кыйммәтләнгән. Бәяләр артуның сәбәпләре билгеле. Иң беренче чиратта, узган ел кыска гына вакыт эчендә Үзәк банкның төп ставкасы 7,5тән 16 процентка кадәр күтәрелде. Бу исә турыдан-туры халык кесәсенә сукты. Күз күнә машиналарны утильләштергән өчен җыемны да арттырдылар. Әгәр машина сатып алырга җыенасыз икән, озакка сузарга кирәкми. Кичектерүдән мәгънә юк. Бәяләр һәм автомобиль сатып алу шартлары көн саен диярлек үзгәреп тора.

Быелтыр Татарстанда 41,7 мең яңа җиңел машина сатылган.

Иң күп сатылган 5 марка

«Лада» > 17037 данә
«Хавейл» > 4333 данә
«Чери» > 4090 данә
«Джели» > 2199 данә
«Омода» > 1279 данә

«Автомаркетолог» мәгълүматлары

Зөһрә САДЫЙКОВА

КАДЕРЛЕ КҮЧТӘНӘЧЛӘР

ТАТАРСТАН ХАЛКЫ ХӘРБИ ОПЕРАЦИЯГӘ НИЧЕК ЯРДӘМ ИТӘ?

Борчу-мәшәкать дигәнең бар кешене бер учак янына җыярга сәләтле ул. Салкыннан җаның куырылганда сине аңлардай иңнәргә башың саласың бит. Хәрби операция игълан ителеп, егетләребез илне сакларга киткәндә дә, бар халык берләшеп, ярдәмгә ашыкты. Күңеле кушканча һәм булдыра алганча. Кемдер – акчасы, кемдер – гамәле, кемдер сүзе белән кушылды. Балаларын зарыгып көткән әниләр, ирләрен озаткан хатыннар гына түгел, битараф булмаган һәр кеше егетләргә булышуны үзенең бурычы итеп кабул итте. Шулай итеп, бүген яу кырына күчтәнәчләр бар халыкның кул һәм күңел җылысына төренеп кузгала.

Аш / Балтач

Балтач районының Арбор авылы халкы хәрби операциягә беренче көннән башлап ярдәм күрсәтә. Башта хатын-кызлар җыелышып, маскировка челтәрләре бәйләгәннәр, одеял, футболка, носки һәм башка кирәк-яраклар җыеп, госпитальләргә озатканнар, көзен 2 тонна бәрәңге җибәргәннәр. Инде бу көннәрдә яшелчәләр киптереп, аш җыелмалары эшләү белән мәшгульләр.

– Бәрәңге, кишер, чөгендер һәм кәбестәне киптереп, борщ пешерер өчен җыелма әзерлибез. Пешкән итне иттарткычтан чыгарып, аны да киптерәбез. Яшел тәмләткечләр, тозын, борычын да салабыз. Шуларның барысын бер ашлык итеп кечкенә пакетларга тутырып җибәрәбез. Өстенә кайнар су салгач, биш минуттан аш әзер була. Үзебез дә ашап карадык, бик тәмле килеп чыга, – ди бу эшләрнең башында торучы Дилә Гарипова.

Фронттагы егетләрнең хәлен аннан да яхшырак аңлаучы юк, чөнки Дилә апаның улы белән кияве мобилизация башлаганнан бирле яу кырында.

– Улым белән киявем икесе ике якта хезмәт итә. Аларны алып киткән көннәрдә бик авыр булды. Улымның өч баласы булса да: «Әни, китәм. Без бармасак, кем барыр?» – диде. Киявем белән кызым бер бала тәрбиялиләр. Кызым да яу кырындагыларга бик нык ярдәм итә. Безгә инде хәзер алардан килгән хәбәрләр белән генә яшәргә кала, – ди ул.

Дилә Гарипова әйтүенчә, егетләргә ярдәм чыннан да барып ирешә.

– Безнең авыл бик булыша, бу хәлләр кешеләрне тагын да берләштерде. Авылыбыздагы хатын-кызларга, колхоз җитәкчеләренә, авыл җирлеге башлыгына башымны иеп рәхмәт әйтәм. Иптәшем инсульт кичерде, шул сәбәпле кул астымда машинам юк. Җыелган, эшләнгән әйберләрне ничек илтеп тапшырырмын икән, дип борчылып йөрим дә, тиз генә җае чыгып та куя. Хуҗалык эшләрендә дә ярдәмнәрен гел тоеп торам. Карны көрәргә мәктәп укучылары ярдәм итте. Бәйрәм саен бүләкләрен дә биреп торалар. Инде үземә дә – 71 яшь. Улым: «Әни, борчылып, җәфаланып йөрмә инде. Безгә барысы да җитә, ач тормыйбыз», – дип тә әйтә, тик балалар хакына эшләсәм, тынычланып китәм. Булышкач, рәхәт була, – дип, күңеле дә тулып китте ана кешенең.

Күренми торган плащ / Мамадыш

Мамадыш районында республикада беренчеләрдән булып күренми торган плащлар (плащ-невидимка) тегә башлаганнар. Әлеге эшкә алынган активист һәм волонтер Сергей Никитин аңлатуынча, плащка өстәп тегелгән махсус тукыма җылы саклый һәм иң мөһиме – тепловизорлы квадрокоптерларга күренми.

– Мин бик күп тапкырлар солдатлар янында булган кеше һәм әлеге өс киемемнең алар өчен ни дәрәҗәдә кирәк икәнен беләм, – диде ул. – Әлеге плащлар уңайлы, ул кешегә тиз хәрәкәт итү, йөгерү, ату мөмкинлеген бирә. Егетләргә 10–15 көнләп окопларда утырырга туры килә. Аларга бик авыр. Яңгырлы, пычрак һава торышы вакытында да плащлар юеш үткәрми һәм җылы саклый. Моннан тыш, аны яралыларны күтәреп алып чыгар өчен дә файдаланырга була. Бу – күпфункцияле, армия өчен бик кирәкле әйбер.

Әлеге җаваплы эшкә күптән түгел генә алынсалар да, инде унбишне тегеп өлгергәннәр. Финанс мөмкинлекләре булса, күбрәк тә тегәргә әзерләр. Сергей Никитинның төп ярдәмчесе – хатыны Екатерина.

– Без аларны Пойкино авылында тегәбез. Бер көнгә ике плащ тегәргә була. Һәр плащ әзер булган саен: «Тагын бер гомерне саклап кала алабыз бит», – дип сөенәбез. Плащлар сынауны уңышлы узды, тиздән башка районнарга да тегү үрнәкләрен күрсәтергә уйлыйбыз, – диде Сергей Никитин.

Моннан тыш, ул хәрби бәрелешләрдә хәбәрсез югалган солдатларны эзләү белән дә шөгыльләнә, «Улзытон» дип аталган эзләү отрядын җитәкли.

– Мин бу эшләрнең зур масштабта булуын, отрядның республика статусын алуын һәм финанслауларын телим, чөнки бу күбрәк мөмкинлекләр бирер иде. Ә миңа мөрәҗәгать итүчеләр бик күп, – ди ул.

Мунча / Мамадыш

Тагын бер мамадышлы Юрис Шәкүров яу кырындагы егетләргә прицеплы мунчалар ясый.

– Мин сарыклар үрчетү белән шөгыльләнәм. Егетләргә ит җибәрмәкче идем дә, җылыда бозылыр, дип, тәгәрмәчле мунчаларга тотынырга булдым. Кулым эш белә, барлык эш коралларым бар. Район башлыгы белән киңәштем дә майда эшкә тотындым. Материал алырга акча булса, бик тырышып эшләгәндә, бер мунчаны бер атнада өлгертеп була. Халыкка рәхмәт, бик теләп булышалар, – ди оста.

Мунчаларны, күчереп йөртергә уңайлы булсын дип, шунда ук прицепка утыртып эшли ул. Заказларны төрле оешмалардан кабул итә. Хәтта Россиянең башка шәһәрләреннән дә. Без шалтыратканда җиденче мунчасын өлгертеп атуы иде.

62 яшьлек Юрис абый – профессиональ спортчы, хәйрияче, чишмәләр төзекләндерүче, агачлар утыртучы, спортчы егетләр тәрбияләгән эти. Берничә ел рәттән авыру һәм этиләре махсус операциядә катнашкан балаларга бәйрәмнәр дә уздыра. Кыскасы, ничек булдыра ала, шулай ярдәм итә.

– Андагы егетләрнең барысы да безнең балалар кебек якын. Әти-әниләре аша күп тапкырлар рәхмәтләре килеп ирешә. Узган ел мине «Безнең заман герое» премиясе белән дә билгеләделәр. Ләкин мин үземне герой дип санамыйм, геройларыбыз – яу кырындагы солдатларыбыз. Мин – бары тик бар район халкы ярдәме белән җыелган акчага мунча эшләп бирүче генә. Битараф булмаган халыкка рәхмәт. Эшләгән өчен бер тиен акча да сораганым юк. Ун мунча эшләп җибәргәч, «ПАЗик» автобусын мунча итеп көйләп, аны госпитальгә җибәрергә ниятлим, – диде ул.

100 кг чәкчәк / Чаллы

Чаллы шәһәрендә яшәүче Мәдинә Мөхәммәтҗанова хәрби операциядәге егетләргә 100 кг чәкчәк пешереп җибәргән.

– Мин күп еллар заказга чәкчәк пешерәм. Илдә шушы хәлләр башланган елның ноябрендә, күңелем кушуы буенча, әлеге татлы ризыкны әзерләргә бул-

дым. Беренчесендә кызым белән бергәләп ике көндә 20 кг чәкчәк пешердек. Анысын җибәргәч, декабрьдә тагын 10 кг әзерләдек. Шуннан соң тукталып тордык да августта тагын 30 кг пешердек. Октябрьдә 60 яшемне тутырдым. 60 яшемә 60 кг чәкчәк булсын инде, дигән идем дә, аннары шуңа өстәп, тагын 40 кг пешердек. Шулай итеп, бер ел эчендә барлыгы 100 кг чәкчәк пешереп озаттык егетләргә, – диде ул.

Без шалтыратканда да дус хатыннары белән 45 йомыркага чәкчәк пешерүләре иде.

– Мин боларның берсен дә пиар өчен эшләмим, ә ихластан үземнең өлешемне кертәсем килде. Улым, сәламәтлегенә бәйле, армиядә хезмәт итмәде, якын танышлар арасында да солдатлар юк, ләкин мин барыбер читтә кала алмадым, – диде Мәдинә ханым.

Чәй җыелмасы / Саба

Саба районының Иләбәр авылында яшәүче Гүзәл һәм Эдуард Федоровлар өч бала тәрбияли. 10 яшьлек уллары ДЦП авырулы, аңа да игътибар күп кирәк, тик авырлыкларга карамастан, хуҗабикә солдатлар өчен чәй җыелмалары әзерләүгә керешкән.

– Мин «Хәят» хатын-кызлар оешмасына керәм. Шуңа күрә мондый хәйрия эше минем өчен ят түгел. Бу юлы да, мәрхәмәтле кешеләр ярдәме белән егетләребезгә ярдәм кулы сузарга булдым. Бер атна элек «Ватсап»ка: «Теләче районында менә шундый җыелмалар эшләгәннәр. Әйдәгез, без дә тырышыйк әле», – дип язуым булды, шунда ук картама акча күчә башлады. Нәтиҗәдә бик тиз арада 30 мең сум акча җыелды. Теләгемне күтәреп алып, ярдәм кулы сузган һәркемгә чиксез рәхмәтлемен. Акчага чәй, каһвә, төрледән-төрле кәнфит, печеньелар сатып алып, 408 җыелма тупладык. Боларның барысын да кызым белән башкардык. Ирем дә ярдәмнән читтә калмый. Товарлар алырга, җыелмаларны илтеп бирергә булыша. Ул ризалык бирмәсә, бу эшләр барып та чыкмас иде, – ди ул.

Әзер җыелмаларны ике гуманитар ярдәм машинасы белән җибәргәннәр, бераз акча җыелгач, тагын юлламакчылар. Билгеле, мондый мәрхәмәтле эшләрдә кешеләрдән җыелган акча гына түгел, үзләренеке дә кушыла.

– Без җыелмаларны, бар тик үзебезнең район егетләренә генә барып ирешсен, дип әзерләмибез. Без кемгә файдасы тисә дә шат. Әле барып ирешмәсә дә, солдатларның әниләреннән, хатыннарыннан рәхмәт сүзләрен инде ишетәбез, – ди ул.

Мазь / Азнакай

Азнакай районының Зур Сукаеш авылда яшәүче Ләйсәнә Вәлиева солдатларның бит, кулларын суыктан саклар өчен, мазьлар әзерли. Аңа кадәр солдатларга оекбашлар бәйләп җибәргән ул.

– Хәзер бу эшне үзем оештырам. Якын-тирә авыллардагы хатын-кызларга җепләр алып кайтып бирәм дә, оекбашларны алар бәйли. Ә мазьларны күптән түгел генә эшли башладым мин. Ялга кайткан бер солдатның җилдә ярылып, «чебиләп» беткән битен күрдем дә, дәваларга дип, үзем ясаган мазьны бирдем. Сөртте дә: «Ләйсәнә апа, бигрәк әйбәт бит бу!» – диде. Шуннан соң, мин бит моны ясап, гуманитар ярдәм белән дә озата алам, дип уйладым, – дип сөйләде ул.

Тагын да файдалырак булсын дип, интернеттан алган рецептны үзенчә үзгәртеп эшли Ләйсәнә Вәлиева. Беренчел чыганактагы көнбагыш маен җитен маена алыштыра, чөнки анысы тагын да файдалырак. Аңа йомырка сарысы, прополис, балавыз, Алтай мумиёсын һәм яраларны төзәтсен өчен стрептоцид порошогын куша. Бер ай эчендә 300дән артык банка мазь ясап өлгергән.

– Актаныш, Кукмара, Саба районнары кызларын да шундый мазьлар ясарга өйрәттем. Минем социаль челтәрләрдә «халык медицинасы» дигән төркемем бар. Күп мәгълүматны шуның аша таратам. Кечкенә банкалар алып килүчеләр дә бар. Язылучылар арасында да, авылдашлар, райондашлар арасында да акчалата ярдәм итүчеләр булды. Тик мазьларның күпчелеген бары тик үз акчама гына эшлим. Мазьларны сатам да, аннан кергән акчага тагын продукция алам. Мәгълүматны мактану өчен дип таратмыйм, ә күбрәк халык җәлеп ителсен иде, дип тырышам, – ди ул.

Ләйсәнә Вәлиева моңа кадәр укытучы булып эшләгән. Яу кырында элеккеге укучылары да, авылдашлары да бар.

– Мин андагы балаларны бик кызганам. Алар турындагы уйларым башымнан китеп торганы юк. Җылы урыныма килеп ятсам да: «Мин җылыда ятам, алар бит суыкта тора. Ашадылар микән бүген?» – дип уйлыйм. Уйлаган саен күңелем тула. Бар әйберебез бар, без дә булышмасак, кем булышыр аларга? Аз гына буш вакыт барлыкка килсә, чималым булса, шушы мазьларыма тотынам. Этикеткаларын ирем, балалар белән бергәләп ябыштырабыз. Бу мазьлар фронтка әле яңа гына китте. Ялга кайтучылар аша да 10–15 банка тыгып җибәрәбез.

Алга таба тамак авыртканда суыра торган имбирле, лимонлы, үләнле кәнфитләр эшләү нияте дә бар Ләйсәнә ханымның.

Окоп шәме / Кайбыч

Ярдәмнән Кайбыч халкы да читтә калмый. Кирәк-яраклар, акча да җыйганнар, хәзерге вакытта исә алар окоп шәмнәре һәм файдалы үләннәрдән чәйләр әзерләү белән мәшгульләр.

– Бик күп авыллардан үзем җитәкли торган «Салават күпере» спорт-сәламәтләндерү комплексына чәйләр, шифалы үләннәр алып киләләр. Без аларның барысын да кечкенә пакетларга салып, әзерләп җибәрәбез. Хуш исле үләннәрен дә, кипкән җимешләрен дә, кара һәм яшел чәйләрен дә салабыз пакетларга. 15 февральгә кадәр көн саен менә шушы эшләр белән шөгыльләнергә уйлыйбыз, – ди «Ак калфак» хатын-кызлар оешмасы җитәкчесе Җәмилә Сәгыева. – Кызларыма бик зур рәхмәт. Алар, буш вакытлары булуга, токмач та кистеләр, чәкчәк тә, тортлар да пешерделәр. Бер хезмәткәребезнең улы хәрби операциядә хезмәт итә. Ул әнисе аша бөтен кешегә рәхмәт әйтеп җибәрде. «Әни, өй токмачы белән аш пешереп ашадык, чәкчәк белән чәй эчтек. Өйгә кайткан кебек рәхәт булды», – дип әйткән.

Моннан тыш, алар окоп шәмнәре ясый. Аның өчен парафин сатып алалар, халыктан яшел борчак, кукуруз, сироплы персик-абрикостан калган калай савытлар, балалар ризыклары банкалары җыялар. Бу акциягә авыл җирлекләре дә кушылган.

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Чүт-чүт кенә...

Нәфес микән инде бу, өметнең шундый чыныккан төре электе микән, без һәрвакыт тормыштан күпне көтәбез. Нинди теләк кенә теләсәк тә, Ходайдан нәрсә генә сорасак та, аның күп булуын телибез. Табыннар сый-нигъмәттән сыгылып торсын, дәрт ургылып ташсын, бәхет ишелеп төшсен, байлыкны өеп бирсен…

Барысын да без сораганча биреп торса, бөтен дөнья ишелеп төшкән бәхет, ургылып ташыган дәрт булып кайнап торыр, алар арасында сый-нигъмәтләр, байлыкмөлкәтләр кер юу машинасындагы чүпрәк-чапрак сыман өерелер иде бугай. Ә үзебез, шушы мәрәкәгә исебез китеп, тормышның берәр ышык урынына кереп посар да Ходайдан тагын ниләрдер сорар идек.

Тик тормыш аз гына бүтәнчәрәк корылган. Монда бернәрсә дә ургылып ташымый, барысы да тамып кына тора. Тып-тып, тып-тып… Кипшенгән иренеңә төшкән ялкау яңгыр тамчылары кебек. Сусавыңны да басмый, аяк сузарга да ирек бирми. Барысы да чүт-чүт кенә. Әгәр күпкә өмет итәсең икән, ул, әлбәттә, булачак, бары тик озак көтәргә туры киләчәк. Һәм көтү вакыты кайчагында гомердән дә озынрак булырга мөмкин.

Чүт-чүт кенә булуы җайлырак та аның. Әйтик, сиңа бик ашыгыч рәвештә нәрсәдер сатып алырга кирәк. Тик акчаң җитеп бетми. Чүт-чүт кенә җитми. Кайчагында «җитмәү» белән «булмау» төшенчәләре арасында бернинди аерма да булмый. Ә синең теге нәрсәне сатып аласың килә. Кирәк ул. Дару ул, мәсәлән. Иң якын кешеңне коткару өчен. Һәм син бәргәләнәсең, бөтен тынычлыгың югала, кулыңа эш, тамагыңа аш бармый, күзеңә йокы керми. Һәм кинәт… Бөтенләй көтмәгән-уйламаган җирдән сиңа акча килеп төшә. Күп түгел, чүт-чүт кенә. Әмма теге мохтаҗлыгыңны ямарга ярарлык. Хәзер син теге әйберне ике дә, хәтта бер дә уйлап тормыйча сатып ала аласың. Тиеннәре чүт-чүт кенә, ә шатлыгы чамасыз.

Иң кирәк чакта һәм бөтенләй уйламаган җирдән кергән чүт-чүт кенә акча сиңа бөтен нәрсәдән дә газизрәк булып тоела. Һәрхәлдә, ул көтеп алынган хезмәт хакыннан кадерлерәк, хәтта бик күп тапкыр кечкенә булса да. Акчаны мисалга китерүем аны чор яраткан өчен генә. Бөтен нәрсә дә шулай. Сәламәтлек, мәсәлән. Үтереп сызлаган тешең кинәт басылып кала. Һәм син үзеңне фани дөнья җәннәтенә эләккәндәй тоясың…

Чүт-чүт кенә килгән сөенечкә дә без тау кадәрле итеп шатланабыз. «Пенсияне арттырганнар!» – дип сөенә картлар. Әйе, арттырганнар. Йөз тәңкәгә. Тик аның бит ничә сумга булуы түгел, ә артуы кыйммәт. Хезмәт хакын арттырганнар менә… Әлбәттә, шулай инде. Артуы кыйммәт… Гомумән, дәүләт безгә шулай игелек эшләп кенә тора. Кайберләрен кайберләребез генә күрә инде. Поликлиникаларда бахилларны бушка бирә башлаганнар менә. Шушы чүт-чүт кенә үзгәреш тә зур ярдәм бит инде чирле кеше өчен. Элек аны биш сумга саталар иде. Тегендә бер бахилл сатып аласың, монда берне һәм дару алырга ун сумың җитми кала. Димәк, вакытында дәвалана алмый каласың. Ә хәзер әйбәт. Биш сумлык игелекнең нәтиҗәсе биш кенә сум тормый.

Тырышып санасаң, андый «чүт-чүт»ләрне хәтсез җыярга буладыр әле. Тырышлык кына кирәк. Һәрбер тырышлыкның нәтиҗәсе була. Чүт-чүт кенә. Бәлки, Ходайдан да, башка инстанцияләрдән дә «ишелеп төшкән, өеп бирелгән» нәрсәләр түгел, ә чүт-чүт кенә итеп сорарга кирәктер. Чүт-чүт кенә хезмәт хакын арттыр, чүтчүт кенә сәламәтлекне ныгыт… Һәм чүт-чүт кенә ешрак сорарга…

29 гыйнвар | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.05 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «Кызган казан» 6+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 16.00 «Халкым минем...» 12+
12.00, 22.40 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00 «Семь дней» 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.30 «Сөйләшергә вакыт» 16+
17.30 «Татарстан без коррупции» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «ТатАгроЭкспо-2024» 12+
21.00 «Заман көзгесе» 6+
22.10 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
23.30 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
00.25 «Каравай» 6+
00.50 «Җырлыйк әле!» 12+
01.40 «Татар халык җырлары» 0+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Ком сәгате» 16+
05.35 «Онытa алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00, 00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
12.05, 03.30 «Аулак өйгә дәшкән егет» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 «Заман көзгесе» 6+
17.00, 19.10, 22.20, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
17.30, 00.40 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.35 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
21.55 «Кызган казан» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «Большой дом» 16+
22.50 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
00.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
01.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
03.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «МАСТЕР И МАРГАРИТА» 16+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.20 «Лига в лицах» 12+
06.30 «Всё о главном» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.50, 18.25 Новости
07.05, 18.30, 21.45, 00.45 Все на Матч!
10.05 «Лица страны» 12+
10.25 «Лучшие из лучших» 12+
11.25 Еврофутбол. Обзор 6+
12.35 Специальный репортаж 12+
13.00 «Есть тема!»
14.55 «Громко»
15.55 «География спорта» 12+
16.25 «Паоло Росси. Чемпион и мечтатель» 12+
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. СКА – «Локомотив»
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Салернитана» – «Рома»
01.30 «Что по спорту?» 12+
02.00 Лёгкая атлетика. Мировой тур в закрытых помещениях 6+
04.00 Футбол. Чемпионат Германии. «Боруссия» – «Бохум» 6+

НТВ

04.50 «УГРО» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ШЕФ. МУЖСКАЯ РАБОТА» 16+
22.15 «ЗОЛОТОЕ ДНО» 16+
01.00 «МЕТЕОРИТ» 16+
02.50 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+
03.20 «ВЕРСИЯ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30, 06.05 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.20 «Давай разведёмся!» 16+
08.20 «Тест на отцовство» 16+
10.30, 23.20 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.35 «Порча» 16+
12.55, 01.35 «Знахарка» 16+
13.30, 02.05 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.30 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «СОЛОВЕЙКА» 16+
19.00 «ВЕРОНИКА» 16+
02.55 «СЕЗОН ДОЖДЕЙ» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «Забытые войны России» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 00.45 «СЛЕД СОКОЛА» 12+
13.25, 03.05 «ПСЕВДОНИМ «АЛБАНЕЦ»-2» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Ищу своих» 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.10 «БЕЗ ОСОБОГО РИСКА» 12+
02.30 «Москва фронту» 16+
02.55 «Оружие Победы» 12+

30 гыйнвар | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «КАЙДА СИН?» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15, 00.25 «Если хочешь быть здоровым» 16+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00 «Татар халык җырлары» 0+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Сибирь» – «Ак барс» 6+
18.00 «Казаннан – Казанга» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «ТатАгроЭкспо-2024» 12+
21.00 «Ватандашлар» 16+
23.00 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.40 «Башваткыч» 12+
01.35 «Татар халык җырлары» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Онытa алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 18.20, 23.10, 04.20 «Җырлыйк әле!» 12+
09.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
03.30 «Яшәү көче килә җырларыннан» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «Большой дом» 16+
22.50 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
00.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Хоккей не футбол» 16+
01.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Кот Шрёдингера» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Россия и Запад на качелях истории» 16+
03.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Гайдай 100» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «МАСТЕР И МАРГАРИТА» 16+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.20 «Лига в лицах» 12+
06.30 «География спорта» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.50 Новости
07.05, 14.55, 18.15, 21.15, 00.00 Все на Матч!
10.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
10.25 «Лучшие из лучших» 12+
11.25 Бокс. Bare Knuckle FC 16+
13.00 «Есть тема!»
15.55 Хоккей. OLIMPBET Чемпионат МХЛ. «Снежные Барсы» – «Красноярские Рыси»
18.45 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Нефтехимик» – «Лада»
22.00 Дартс. PARI Международная лига. Тур 1
01.00 Матч! Парад 6+
01.30 «Что по спорту?» 12+
02.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «МИНСК» – «ПАРМА» 6+
04.00 Футбол. Кубок португальской лиги. Финал 4-х 6+

НТВ

04.50 «УГРО» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ШЕФ. МУЖСКАЯ РАБОТА» 16+
22.15 «ЗОЛОТОЕ ДНО» 16+
01.00 «МЕТЕОРИТ» 16+
03.25 «ВЕРСИЯ» 16+

ДОМАШНИЙ

07.30 «Давай разведёмся!» 16+
08.30 «Тест на отцовство» 16+
10.40, 23.20 «Понять. Простить» 16+
11.55, 00.35 «Порча» 16+
13.00, 01.35 «Знахарка» 16+
13.35, 02.05 «Верну любимого» 16+
14.10, 02.30 «Голоса ушедших душ» 16+
14.45 «БЫВШИЕ ЛЮБИМЫЕ» 16+
19.00 «ОТВЕРЖЕННАЯ» 16+
02.55 «ОДНО ТЁПЛОЕ СЛОВО» 16+
06.05 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 00.50 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ» 12+
13.25, 03.00 «ПСЕВДОНИМ «АЛБАНЕЦ»-2» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Улика из прошлого» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.10 «АТЫ-БАТЫ, ШЛИ СОЛДАТЫ...» 12+
02.25 «Москва фронту» 16+
02.45 «Оружие Победы» 12+

Приложение
к постановлению Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан от 24 января 2024 г. № 35/269

Сообщение

Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан о приеме предложений по кандидатурам членов избирательной комиссии с правом решающего голоса в состав территориальной избирательной комиссии Советского района города Казани Республики Татарстан на вакантные места

В связи с прекращением полномочий двух членов территориальной избирательной комиссии Советского района города Казани Республики Татарстан с правом решающего голоса, руководствуясь статьями 22, 26 и 29 Федерального закона «Об основных гарантиях избирательных прав и права на участие в референдуме граждан Российской Федерации», статьями 11, 15 и 18 Избирательного кодекса Республики Татарстан, Центральная избирательная комиссия Республики Татарстан объявляет прием предложений по кандидатурам для назначения членов территориальной избирательной комиссии Советского района города Казани Республики Татарстан с правом решающего голоса.

Прием документов осуществляется в период с 27 января 2024 года по 30 января 2024 года по рабочим дням с 09.00 до 18.00 часов (перерыв на обед – с 12.00 до 13.00 часов), по адресу: ул. Батурина, д.7Б, г. Казань, 420111 (контактные телефон: 8(843) 292-84-33).

При внесении предложений по кандидатурам в состав территориальной избирательной комиссии на вакантное место необходимо руководствоваться Постановлением Центральной избирательной комиссии Российской Федерации от 15 марта 2023 г. № 111/863-8 «О методических рекомендациях о порядке формирования территориальных, окружных и участковых избирательных комиссий». Образцы необходимых документов размещены на официальном сайте Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

Белдерү

Водительские права тракториста, выданные СПТУ-87 г. Мамадыш в 1988 году на имя Закирова Халима Миннахметовича, 24.10.1969 г.р., в связи с утерей считать недействительными.

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БУЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

АКЫЛГА УТЫРТА

Үз гомерендә бер тапкыр булса да аның белән очрашмаган кеше сирәктер. Аның сызлавы иң зур җәзаларның берсе сыман. Сүзебез акыл теше турында. Аны алдыру мәҗбүриме? Акыл теше яндагы тешләрне бозамы?

Тәҗрибәле теш табибы, хирург Илдар ГАЙНУЛЛИН шул сорауларыбызга ачыклык кертте.

Кайчан чыга?

Һәр очрак – индивидуаль. Акыл тешенең чыгуы аның казналыкта ничек урнашуына, казналык зурлыгына да бәйле. Шулай да ярдәм сорап мөрәҗәгать итүчеләрнең яше буенча чамалап карасак, акыл теше уртача 20–25 яшьтә чыга дип әйтергә була.

Ничәү була?

Кешедә, гадәттә, дүрт акыл теше була. Сирәк кенә булса да аларның саны дүрттән арткан очраклар да күзәтелә. Акыл теше чыкмаган кешеләр дә бар. Бу казналыкта акыл теше башлангычы булу-булмауга бәйле. Әгәр акыл тешләренең башлангычы юк икән, димәк, гомердә дә андый теш чыкмаячак. Акыл теше башкаларыннан казналыкта урнашу рәвеше белән генә аерыла. Ул тишеп чыкмыйча, казналыкта гына ятарга да мөмкин. Ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән кешеләрнең күбесендә акыл теше горизонталь рәвештә урнашкан була. Андый тешне җитди операция ярдәмендә генә алырга мөмкин.

Яндагысын бозамы?

Янәшәдәге тешләрнең бозылуы иң беренче чиратта тешләрне тиешенчә чистартмауга бәйле. Теш щеткасы еш кына сигезенче булып урнашкан акыл тешенә, аның алдындагы җиденче тешкә кадәр керен җитә алмый. Нәтиҗәдә ике арага ризык калдыклары кереп тула. Бу тешләрне тиешенчә чистартып, чайкап бетерү дә кыенлаша. Шул рәвешле акыл теше дә, аның янәшәсендәге теш тә бозыла.

Кайчан алдырырга?

Моны ортодонт хәл итә. Әйтик, кешенең тешләү рәвешен (прикус) үзгәртү өчен акыл тешен алдырырга кирәк булу бар. Ортопедка мөрәҗәгать иткән кеше дә шундый ук киңәш ишетергә мөмкин. Тешне ямап кына котылып булмаган очракта да аны алдыру мәҗбүри. Акыл теше үлекләгән булса да, аны алдырырга кушабыз.

Алдыру мәҗбүриме?

Акыл теше борчымаса, кеше киләчәктә брекет кияргә җыенмаса, аны алдырмасаң да була. Мин үзем акыл тешен берәрләп кенә алырга тырышам. Әйтик, кешедә дүрт акыл теше бар ди. Башта бер яктагы акыл тешен алып, ул җәраһәт төзәлгәч, икенче килгәндә каршы яктагысын алабыз. Өске акыл тешләре җиңелрәк алына. Яра да тизрәк төзәлә. Аскы акыл тешләрен исә гадәттә катлаулы операция ярдәмендә алырга туры килә. Әйткәнемчә, аларның күбесе горизонталь рәвештә урнашкан була. Шуңа күрә тешне кисәкләргә бүлгәләп алырга туры килә. Акыл тешен алдырудан куркасы юк. Авыртуны баса торган заманча чаралар ярдәмендә иң катлаулы дип саналган операция дә куркыныч түгел. Табиб кушканнарны җиренә җиткереп үтәсәң, теш урыныдагы яра да тиз төзәләчәк.

vk.com

Кисәтеп буламы?

Теләсә кайсы теш сызлауны кисәтү өчен ярты елга бер тапкыр теш табибына күренеп тору зарур. Тешләрнең ортопантомограмма (ОПТГ) сурәтен төшереп, аларның торышын тикшерергә кирәк.

АКЫЛ ТЕШЕН АЛДЫРГАН КЕШЕГӘ КИҢӘШЛӘР

1 Теш алдыргач, ике сәгать дәвамында ашаудан тыелып торырга кирәк. Бер тәүлек дәвамында артык кайнар, салкын, каты ризыклар ашарга ярамый.

2 Яраны тышкы яктан җылыту тыела.

3 Битнең теш алдырган ягы шешеп чыкмасын өчен, берәр сәгать дәвамында салкын әйбер куеп тору да зыян итмәс.

4 Акыл теше алдырган көнне физик эш эшләүдән, мунча керү, якынлык кылудан да тыелып торырга туры киләчәк.

5 Бу көнне канны сыеклата торган дарулар эчү тыела.

6 Теш алдырган урын борчымаса да, күңел тынычлыгы өчен кабат табибка күренеп кайту комачау итмәс.

Үзем сынадым

Хондрозым бетте

Яшь чактан бирле хондроздан интегәм. Авырту көчәйгән вакытта шушы ысулның файдасын күрәм. Сез дә кулланып карагыз әле. 10 аш кашыгы тоз өстенә 20 аш кашыгы үсемлек мае агызам да, шуны яхшылап болгатып, берничә көн тотам. Ак төстәге масса барлыкка килә. Аны һәр көнне муенга сылап, массаж ясыйм. Башта ике-өч минут кына, һәр көнне икешәр минут өстәп барып, егерме минутка кадәр арттырасы. Массаж ясап бетергәч, муенны дымлы җылы сөлге белән сөртәм. Ун процедурадан соң алга китеш сизелә.

Альбина ЗӘБИРОВА

Табигать даруханәсе

Сулыш юллары ялкынсынудан

500 г әрчеп туралган суган, 50 г бал, 40 г шикәр комын 1 литр суга салып болгатып, сүрән утта 3 сәгать тәнәтергә кирәк. Шул төнәтмәне көнгә 3 тапкыр берәр аш кашыгы кабарга киңәш итәлә.

Ютәлдән

Уртача зурлыктагы чөгендерне яхшылап юып, өстен капкач төсле итеп кисеп алыгыз. Шунда тирән булмаган чокыр ясап, 2 чәй кашыгы шикәр комы салыгыз да микродулкынлы мичтә 5 минут пешереп алыгыз. 20–25 минут духовкада пешерсәң дә ярый. Барлыкка килгән сокны кичен, иң яхшысы йоклар алдыннан эчегез. Беренче тапкыр эчкәннән соң ук файдасы тиячәк. Аны балалар да бик яратып эчә.

Бөердән таш чыгару өчен

400 г миләшне изеп, шуңа 2 литр кайнаган су һәм берәз шикәр комы салырга, дүрт сәгатьтән соң болгатып, сөзеп эчәргә кирәк. Эч катканда берничә атна буена көнгә өч тапкыр 70–100 грамм шундый сок эчәргә киңәш итәлә.

Азканлылыктан

Ике аш кашыгы кызыл миләш җимешен ике стакан кайнар суга салып, бер сәгать төнәткәч, сөзәргә. Шуны көн буена өч-дүрт тапкыр аз-азлап эчәргә кирәк.

Абау!

ЧИЯ КОТКАРА

Чия буыннар сызлавын бетерә. Американың Мичиган университеты галимнәре шундый ачыш ясаган. Көненә 20 данә чия ашау буыннар сызлавын бетерә, ди алар. Чиягә кызыл төс бирә торган матдәләр ялкынсынуны дәвалауда аспиринга караганда да нәтиҗәлерәк икән.

Киңәш

ЧИСТА БУЛСЫН!

Бит тиресе сәламәтлеге өчен, бизәнү әйберләренең чиста булуы да мөһим.

✓ Пыяладан ясалган бизәнү әйберләрен кер порошогы кушылган суда юарга һәм чиста суда чайкарга кирәк.

✓ Пластмасс бизәнү әйберләрен сабынсыз, порошоксыз суда юыгыз.

✓ Гәрәбә, фил сөягеннән ясалган бизәнү әйберләрен сабынлы җылы суда юа аласыз. Фил сөяге саргайса, 10 минутка хлорлы суга салып торырга була.

✓ Агачтан ясалган бизәнү әйберләрен майлы кул белән тотмаска, крем тидермәскә тырышыгыз.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА

ТУФРАГЫ ДА, ОРЛЫГЫ ДА МӨҺИМ

Мәшәкатьле дә, күңелле дә бакча сезоны җитә. Эшне нәрсәдән башларга соң? Орлык, туфрак сайлаганда нәрсәләргә игътибар итәргә? Иң беренче нәрсәне утыртырга?

Укучыларыбызны борчыган сорауларга җавап табарга бакчачы блогер Рәмзия ӘХМӘДУЛЛИНА ярдәм итте.

:: Рәмзия ханым, орлык хәстәрен күрер вакыт: аны сатып алсаң яхшыракмы, әллә әзерләвең хәерлерәкме? Сатып алганда кайдан алсаң яхшырак?

– Мин орлыкны гел бер җирдән генә алам дип әйтә алмыйм. Махсус кибетләрдән дә, үзем сынаган сортларны базардан да сатып алам. Үзем әзерләгәннәре дә бар. Орлыкларны базар янындагы махсус кибетләрдә берничә кеше бергә җыелып, ташламалы бәядән дә алырга була. Орлык сайлаганда кабындагы рәсеменә кызыгып алучылар да була. Аның гадәти каптагысыннан бер аермасы да юк, орлык саны да, тишелеше дә бер үк, тик кабы өчен артыграк кына түлисең.

:: Сатудагы итләч татлы борычларның орлыгын алып утыртсаң, үсәме?

– Үсә. Тик алар соң өлгерә, шунлыктан аларны иртә утыртырга кирәк. Мин дә аларны ел саен утыртам. Көндәлегемдә 26 гыйнварда утыртырга дип теркәп куйганмын, димәк, вакыт җиткән. Ачы борычны да, татлысын да хәзер утырту яхшы. Әлбәттә, җылы теплица тотучылар иртәрәк тә чәчә ала. Февральдә чәчсәң, орлыгы алынган кибет борычлары сентябрьдә генә өлгерә. Орлыкны киптереп тормый гына чи килеш утыртканда ул тизрәк тә тишелә.

:: Орлыкларны ничек эшкәртеп утыртырга? Аның ашламалымы икәнлеген кайдан белергә?

– Ашлама белән эшкәртелгән кибет орлыкларының төсе табигый булмый, аны шуннан аерып була. Ә эшкәртелмәгән яки үзең әзерләгән орлыкны эшкәртми утыртырга киңәш итмәс идем. Чөнки авыру, корткыч һәм бактерияләрдән саклау хәстәрен алдан күрергә кирәк. Орлыкны утыртыр алдыннан ярты сәгать чамасы водород перекисе яки сыек марганцовка эремәсендә тотарга кирәк. Аннары чиста су белән чайкап алабыз да утыртабыз.

:: Әрәм булмасын дип, тишелгән көлшәләрнең барысын да утырту кирәкме?

– Тишелгәннән соң аларның иң матур, иң көчле һәм сәламәтләрен генә күчерү өчен сайларга кирәк. Чөнки ул – безнең ел буе кулланасы ризыгыбыз, яхшының уңышы да мул була.

:: Кабында F1 дип язылган гибридлар өлгергәннән соң, орлык алырга ярамый, диләр.

– Гибридлардан орлык алырга була, ул чәчәк тә атачак, җимеш тә бирәчәк, тик сез теләгән нәтиҗәне генә бирмәячәк. Чөнки аның уңышы күпкә начар булачак.

:: Чәчү өчен туфрак сайлаганда нәрсәгә игътибар итәргә?

– Яшелчәләрнең уңышы орлыктан гына тормый. Ашлама әсәре булмаган туфрактан мул уңыш алып булмый. Мин үзем торфлы арзанлы туфракка «Живая земля» кушып утыртам. Бик уңдырышлы, минералларга бай булса да, «Живая земля» җиңел булганлыктан, анда дым бик тиз бетә. Шунлыктан ике туфракны кушу – иң яхшысы. Орлык чәчү өчен тагын урман туфрагы, кычыткан үскән урындагы туфрак яхшы.

vk.com

:: Туфракны, орлык чәчкәнче зарарсызландыру өчен, мичкә дә тыгып куйгалыйлар. Алай итү чыннан да файдалымы?

– Корткычлардан, аларның личинкаларыннан котылу өчен иң кулай ысул. Шулай ук кайнап чыккан су белән эшкәртүчеләр дә бар. Мичкә тыгу туфракны корткычлардан гына түгел, файдалы минераллардан да арындырып, аны ярлыландыра. Шуңа күрә андый туфракка чәчкәндә аны даими тукландырып торырга кирәк. Андый туфрак исә авыр була, шуңа күрә аны да «Живая земля» белән буташтырып утыртырга кирәк.

:: Кибет туфрагының яраклылык вакыты буламы?

– Әлбәттә, аны сатып алганда әзерләнү вакытын карап алсагыз яхшы. Чөнки әллә ничә ел ятып сөрсегән балчыкка караганда яңасы үсемлекләр өчен файдалырак булачак.

:: Туфрак составын яхшырта торган препаратлар куллану кирәкме?

– Үзем «Вермикулит» белән «Перлит» кулланам. Алар туфракны кислород белән баету һәм дым саклау өчен ярдәм итә. Ә корткычлардан арындыру өчен, туфракны «Фитоспорин» белән эшкәртергә була. Гадәттә, аны кибетнекенә түгел, ә үзең әзерләгән туфракка сибәләр.

:: Фитолампа куллану кирәкме?

– Булса бик әйбәт! Тик аны дөрес кулланырга кирәк. Фитолампа үсентедән 15–20 см биеклектә булырга тиеш. Аннан биегрәк булса, аның бер файдасы да юк, ул бары яктылык чыганагы гына булып тора.

Тәмле булсын!

«ЗАТЛЫ» САЛАТ

Гөлгенә Әүһәдиева рецепты

Кирәк: *руккола, шпинат, черри помидоры, ысланган каз, әфлисун.*

Болгату өчен соуска кирәк: *3 аш кашыгы әфлисун согы, 1 чәй кашыгы горчица, 1 чәй кашыгы бал, 1 чәй кашыгы соя соусы, тәменчә тоз белән кара борыч.*

Помидор, каз, әфлисунны фотодагыча турап, яшел тәмләткечләрне салып, соус белән болгатабыз. Бик тиз ясала һәм бик тәмле була.

Хуҗабикәгә

Чистарынабыз

Яңа елга кадәр бу эшләрне башкарып өлгермәсәгез, хәзер менә дигән вакыт. Кыскасы, язга чыкканчы чистарынабыз! Түбәндәге бөтен әйберне ташлыйбыз:

✓ бөтен ватылган, кителгән, парсыз савыт-сабаларны, кулланылмый торган иске кәстрүл, табаларны, капкачларны, тартмаларны;
✓ башланган да ташланган косметика, парфюм ише әйберләрне;
✓ яраклылык вакыты чыккан даруларны;
✓ ябыккач яки тазаргач киярмен әле, дигән киемнәрне;
✓ искереп, бөтенләй рәте калмаган сөлге, урын-җир кирәк-яракларын, аш бүлмәсендәге чүпрәк, губка ише әйберләрне;
✓ тотылмый торган сумка, аяк киеме, чаңгы, тимераяк ише әйберләрне;
✓ иске квитанция, түләү кәгазьләрен.

Белеп тор!

Гөлләргә «стресс» кирәк

Орхидея, декабрист, миләүшә күптәннән чәчәк атмаса, аңа «стресс» ясап алырга киңәш итәләр.

24 градус һәм аннан да югарырак температуралы бүлмәдә гөлләр «ялкаулана». Чәчәк атсын өчен, аларны 15 минутка +8...–10 градуслы салкынча урынга куеп алырга кирәк. Моны айга бер-ике тапкыр кабатлап алырга мөмкин. Әлеге ысул яран гөлләр өчен бармый.

АКТАН ЗАРАР ЮК

Көнчелек – адәм баласының күңелендә оялый торган иң төп хисләрнең берсе. Бер яктан тормышны җайласа, икенче яктан җимерергә дә мөмкин ул. Алтын урталыкны ничек табарга? Хөсетлек әҗер-савапны киметәме?

«Рөстәм» мәчете имам-хатыйбы Исмәгыйль хәзрәт БИККИНИН белән шул хакта сөйләштек.

:: Хөсетлек җанны ашаса, ни эшләргә?
– Җаныбызга, йөрәгебезгә дәва салучы – Аллаһы Тәгалә. Шуңа күрә хөсетлек җанны ашаса, Раббыбызга ялварып, дога кылып, дәваланырга кирәк. Икенчесе – зекер. Өченчесе – истигъфар, дүртенчесе – салават әйтү. Болар бар да кешенең күңеленә яхшы тәэсир итә. Пәйгамбәребез Аллаһы Тәгаләдән: «Яраббым, бир миңа шундый калебне, кайсы синә карата итагатьле булыр», – дип, Аллаһы Тәгаләдән сораган. Әлеге начар уйны күңелдәнниндидер файдалы эш эшләп тә чыгарырга мөмкин. Тәһарәт алу, намаз уку да файдалы физик эш санала. Үзебезнең булган нигъмәтләр турында уйлап, фикерләп алу да файдалы булачак. Андый чакта картлар, ятимнәр йортына барып кайтсаң да, күп нәрсәгә карашың үзгәрәчәк. Күңелдә бу яман хис барлыкка килмәсен өчен, кеше башка берәүнең мал-мөлкәтен, матурлыгын күргән очракта «сөбханалла» дип әйтергә тиеш. Аллаһыны искә төшергән шушы мәлдә аның күңеленә шайтан вәсвәсәсе кермәячәк.

:: Көнчелек, хөсетлек кешенең гомер буе җыйган әҗер-савапларын юкка чыгарырга мөмкин, диләр. Бу шулаймы?
– Кеше Аллаһы Тәгаләгә ризасызлык белдерүе аркасында диннән дә чыгарылырга мөмкин. Мәсәлән: «Аллаһы Тәгалә фәләнгә генә бирә инде барын да», – дип әйтеп куярга мөмкин ул. Шул рәвешле кешедә Аллаһы Тәгаләнең гаделлегенә, камиллегенә карата яман хис, хәтта нәфрәт барлыкка килергә мөмкин.

Әгәр без яман сүзләр сөйләсәк, кешеләр турында начар уй-фикердә булсак, Аллаһы Тәгаләгә карата канәгатьсезлек белдерсәк, хаҗ, зәкят, сәдакаларыбыз сәбәпле алынган әҗер-савапларыбыз да юкка чыгачак. Шуңа күрә ислам дине тән чисталыгына гына түгел, җан чисталыгына да зур игътибар бирә.

Пәйгамбәребез бер хәдисендә: «Кыямәт көнендә муфлис (банкрот) булачак. Алар мал-мөлкәттән банкрот булмас, ә изге эшләреннән колак кагарлар. Чөнки алар кешегә зарар салырлар, яла ягарлар һәм изге эшләрен таратырлар», – дигән.

vk.com

:: Билгеле булганча, ак көнләшү белән кара көнләшүне аералар. Ак көнләшү хәерлерәк санала. Шулай да дин ягыннан караганда ул гөнаһ саналмыймы? Ак булса да, көнләшү бит. Көнләшү булгач, Ходай биргәнгә риза булмау кебек була түгелме?
– Ак көнләшү – көнләшү генә түгел. Кешедә күргән изгелек тә кимемәсен, шул ук вакытта ул шушы изгелеккә катнашсын, хәтта күбрәк эшли алсын дигән уй барлыкка килсә, бу ак көнләшү түгел, хәерле теләк дип атала. Ак көнләшү безгә бу дөньяда ныграк эшләргә, күбрәк белем алырга, балаларыбызны тәрбияләргә, дин ягыннан үсәргә этәргеч бирә, киләчәккә дөрес максатлар куярга ярдәм итә. Шуңа күрә ак көнләшү гөнаһ саналмый.

:: Әгәр кеше малын көнчелек, хөсетлек хисабына тапкан икән, ул хәләл буламы?
– Хөсетлек кешенең йөрәген ялап ала, аны, киресенчә, яхшы, файдалы эшләрдән туктата, аңын исертә. Көндәлек тормышта күршең алган әйберне алу, аңа кызыгып, ниндидер эш башкару киң таралган. Күпләр моны хөсетлек дип кабул итә. Әмма бу көнләшү түгел, бер-береңә карап, ниндидер яхшы эшкә омтылу. Әйтик, кеше үзенекен буйыйсы урынга, күршесенең буялган коймасын ватса, менә бу очракта ул хөсетлек була. Шуңа күрә узышу белән хөсетлекне бутарга ярамый. Әгәр кеше үз малын хәләл юл белән таба икән, бу – хөсетлек түгел, ә кешеләр арасында узышу, тырышу, максатчанлык билгесе.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Бу мөһим!

✓ Ислам дине кеше күңелендәге тынычлыкка комачаулаган нәрсәләргә каршы килә. Хөсетлек – шуларның берсе. Икенче кешенең уңышын, мал-мөлкәтен, дәрәҗәсен күреп, аңа карата ризасызлык белдерә һәм аның күңелен кара уй-фикер баса. Ислам динендә бу гамәл берничә сәбәптән тыела. Беренчедән, хөсетлек аркасында кеше Аллаһы Тәгалә бу дөньяда бүләп биргән мал-мөлкәт, дәрәҗә, нигъмәтләргә карата ризасызлык белдерә. Мондый кешедә мал-мөлкәткә, нигъмәткә ия кешенең хакын төшерү хисе дә барлыкка килә. Хөсетлек хис белән генә тукталмый. Фигыль һәм сүзгә дә көчә башлый. Кеше аның дәрәҗәсен төшерү өчен гайбәтен сөйләргә, аңа яла ягарга мөмкин. Мал-мөлкәтенә зарар ук китерергә мөмкин.
✓ Пәйгамбәребез хәдисләрендә хөсетлек турында еш телгә алына. Шуларның берсендә: «Хөсетлек ут шикелле сезнең изге эшләрегезне яндыра», – диелә. Шул рәвешле көнчелек, хөсетлек кешенең бөтен изге гамәлләрен, тоткан уразаларын, әҗер-савапларын ут шикелле юкка чыгара. Икенче бер хәдистә пәйгамбәребез аны иманыбызны кыручы лезвие белән дә чагыштыра. «Бер-берегезгә хөсетләнмәгез, бер-берегезгә арка белән борылмагыз, бер-берегезнең сәүдәләрен бозмагыз. Мөселманнар булыгыз, берберегезгә кардәшләр булыгыз», – ди ул. Хөсетлекнең тагын бер куркыныч ягы бар. Ул сихер, күз тиюгә дә китерә ала. Табиблар хөсетлекнең кешедә чир китереп чыгаруын да искәртә.

Февраль аенда намаз вакытлары

Көн саны	Көн исеме	Таң беленә башлый	Кояш чыга	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
1	Пәнҗ	05:29	07:38	14:24	16:16	18:03
2	Җом	05:28	07:36	14:26	16:18	18:05
3	Шим	05:26	07:34	14:28	16:20	18:07
4	Якш	05:25	07:32	14:30	16:22	18:08
5	Дүш	05:23	07:30	14:32	16:24	18:10
6	Сиш	05:21	07:28	14:34	16:26	18:12
7	Чәрш	05:20	07:26	14:36	16:29	18:14
8	Пәнҗ	05:18	07:24	14:38	16:31	18:16
9	Җом	05:16	07:22	14:40	16:33	18:18
10	Шим	05:14	07:20	14:42	16:35	18:20
11	Якш	05:12	07:18	14:44	16:37	18:22
12	Дүш	05:11	07:16	14:46	16:40	18:24
13	Сиш	05:09	07:13	14:48	16:42	18:25
14	Чәрш	05:07	07:11	14:50	16:44	18:27
15	Пәнҗ	05:05	07:09	14:52	16:46	18:29
16	Җом	05:03	07:07	14:54	16:48	18:31
17	Шим	05:01	07:04	14:56	16:50	18:33
18	Якш	04:58	07:02	14:58	16:53	18:35
19	Дүш	04:56	07:00	15:00	16:55	18:37
20	Сиш	04:54	06:58	15:02	16:57	18:39
21	Чәрш	04:52	06:55	15:04	16:59	18:41
22	Пәнҗ	04:50	06:53	15:06	17:01	18:43
23	Җом	04:47	06:50	15:08	17:03	18:45
24	Шим	04:45	06:48	15:10	17:06	18:47
25	Якш	04:43	06:46	15:11	17:08	18:49
26	Дүш	04:40	06:43	15:13	17:10	18:51
27	Сиш	04:38	06:41	15:15	17:12	18:53
28	Чәрш	04:35	06:38	15:17	17:14	18:55
29	Пәнҗ	04:33	06:36	15:19	17:16	18:58

Искәрмә: өйлә намазы – 12.00 сәгатьтә.

Йөгез, бер дога!

ГАИЛӘ КОРЫР ӨЧЕН УКЫЛА

«Раббәнә һәб ләнә мин әзвәәҗинә вә зуррийәтинә куррата әгйун вәҗгалнә лил муттәкыйнә имаама».

Мәгънәсе:
«Раббым! Күңелләребез куанычы, күзләребезнең карасы кебек (затлы, пакь) хатыннар вә балалар бир. Безне саф мөселман халыкларына юлбашчы ит».

(Коръән, 25:74)



Лилия ГЫЙМАЗОВА

Бер сүз җитә

Уйламый әйтелгәне дә, әйтелми калганы да куркыныч. Сүзнең көче дә, тәэсире дә зур – моны һәркем белә, әмма кайчак тиешенчә бәяләми. Сәхифәбездәге яңа сорау – җавап та тормыштагы әһәмиятле сүзләргә багышлана. Бу юлы без җырчы Илнат ФӘРХУЛЛИН белән сөйләштек.

:: Иң кадерле сүз?
– Әни.

:: Бирешкәндә тартып торгызган сүз?
– Бирешмәскә! Көчле, сабыр булырга!

:: Бик каты яралаган, рәнҗеткән сүз?
– Нахак сүз.

:: Әйтәсе килеп тә, әйтә алмый калган сүз?
– «Әти» дип әйтә алмадым...

:: Бүген, хәзер ишетәсе килгән сүз?
– Мин сиңа ышанам.

Аннан-моннан

Узып баручы атна ниләр белән истә калды? Бу сорауга җавап итеп, социаль челтәрләрдәге «кайнар» яңалыкларны тупладык.

Гүзәлем һәм Салават Миңнехановлар сәхнәдән китә? «Мәҗлесләрдәге һәм сәхнәдәге чыгышларны туктаттык. Иҗат икенче юнәлештә дәвам итәчәк. Әлегә без ял итәбез», – дип язган иде Гүзәлем социаль челтәрләрнең берсендә. Үзе белән элемтәгә чыккач: «Бу мәсьәләгә карата әлегә комментарий бирмим», – дип, җавабын кыска тотты ул. Шулай итеп, татар сәхнәсендәге җырлы гаиләләр бергә кимеде...

Татар блогеры 160 мең сум акчасын югалткан. Блогер Резеда Миңнегулованың гаиләсе Таиландта ял иткәндә әнә шундый зур суммадагы акчасын югалткан. «Без бер отельдән икенчесенә күченеп йөрибез. Әйе, карап йөртмәвебезгә үзебез гаепле», – дип язган ул социаль челтәрдә.

Алсу Фазлыева ник елаган? Җырчының гомрә хаҗына китүе турында узган атнада язган идек инде. Бу көннәрдә Алсу изге сәфәргә бәйле сорауларга җавап бирде. «Изге җирдә булудан куңелегездә нинди хисләр йөртәсез?» – дигән сорауга: «Мин еладым. Хисләрне сүзләр белән аңлата да алмыйм. Мондый хәл минем белән беренче тапкыр килеп чыкты», – дип җавап биргән ул. Кайткач, аулык ябу-япмавы турында да кызыксынучылар булган. «Профессиямә бәйле булгач, әлегә әйтә алмыйм. Ләкин бу сорауга җавап алдым», – дигән җырчы.

Илмира Нәгыймова баянда өздерә. Җырчының баянда уйнаган, ә баянчы Ринат Яруллинның аңа кушылып җырлаган видеоязмасы социаль челтәрләрдә яшен тизлегендә таралды. *Күрмәгән булсагыз, түбәндәге QR код аша кереп карый аласыз.*

БЕЗНЕҢ БАТЫРЛАР

Бу юлы сәхифәбездә татарның асыл егетләре – көрәшчеләрнең хәлләрен белешергә булдык. Бер атнадан – 2–3 февральдә каһарман-шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә газетабыз гамәлгә куйган көрәш турниры узачак бит. Турнирга әзерме алар?

«Кеше сөйли инде ул...»

Радик СӘЛАХОВ, турнирның 4 мәртәбә җиңүчесе:
– Күптән түгел имгәндем. Шуңа быел «Манзара» бәйгесенә тамашачы буларак кына килдем. Сакланам, үземне артык бетермәскә тырышам. Алда Җәлил турниры көтә бит, аңа кадәр көч җыярга кирәк. Аннары Татарстан чемпионатына барасы бар. Хәзерге вакытта әзерләнәм, быел туган ягым Зәй командасы өчен чыгыш ясаячакмын. «Үзара сөйләшкәннәр, шуңа Радик көрәшмәгән» ише имеш-мимешләргә килгәндә, әй, кеше сөйли инде ул.

«Туктап торам...»

Раил СӘЛАХЕТДИНОВ, турнирның 4 мәртәбә җиңүчесе:
– Шактый җитди имгәндем, шуңа әлегә ял итәм, көч туплыйм. Кызганыч, быел Җәлил турнирына да тамашачы буларак кына киләчәкмен. Соңгы арада ярышларда, гомумән, катнашканым юк. Бу турнирда биш мәртәбә катнаштым, дүрт мәртәбә җиңдем. Быел катнашмавым белән көндәшләремә җиңү мөмкинлеге бирәм *(көлә)*. Бу ялымны көрәштән бөтенләй китә дип кабул итмәсеннәр иде. Минем бер шулай имгәнеп, бераз туктап торганым бар иде. Келәмгә көч туплап кайттым. Бу юлы да шулай булыр дип өметләнәм. Туктап тору кемгәдер начар, кемгәдер яхшы тәэсир итә бит. Миңа икенчесе кагыла.

«Андый нәрсә булырга тиеш түгел»

Динар КӘРИМУЛЛИН, турнирның 3 мәртәбә җиңүчесе:
– Яңалыклар әллә ни юк. Бу арада көнгә икешәр мәртәбә тренировкага йөрим, Җәлил турнирына әзерләнәбез. Быел дүртенче мәртәбә отарга исәп. Көчле яшьләр үкчәгә басып килә. Көндәшләрне күзәтеп торам: шактый тырышырга туры киләчәк. Соңгы арада көрәш тирәсендә тагын шау-шу барлыкка килә башлады. Сөйләшү-фәлән турында мин электән әйтәм инде: аны җитәкчелек контрольгә алсын иде. Кайсыдыр егетләрнең, үзара сөйләшеп, урын бүлешүен беләләр икән, куып чыгарсыннар ярыштан! Билгеле, Сабан туйларында барысын да күреп бетермәскә дә мөмкиннәр. Көрәшчеләрнең урак өсте – акча эшли торган чоры инде ул. Ләкин төп ярышларда андый нәрсә булырга тиеш түгел.

«Монда бәхет елмая»

Ранис ГАЛИМУЛЛИН, турнирның 3 мәртәбә җиңүчесе:
– Быелгы турнирда катнашырга ниятләп торам. Монысы унынчы тапкыр катнашуым була, ялгышмасам. 5 тапкыр финалда бил алыштым, 3 тапкыр җиңдем. Быел да әзерлек әйбәт, Аллага шөкер. Лаеш командасы ныклап әзерләнә. Команда белән дә, үзебез дә сынатмаска иде инде! Муса Җәлил турнирында җиңүне, беренчелекне алганнан соң кичергән хисләрне бернәрсә белән дә чагыштырып булмый. Монда гел көчлеләр, «иң-иң»нәре килә. Башка көрәшчеләр дә килешер минем белән. Барыбыз да Җәлил турнирында җиңүләрне санап барабыз. Яратам мин бу көрәш бәйгесен. Миңа ничектер бәхет елмая, тиз, җайлы җиңәм. Ә монда җиңү бәхете бик сирәкләргә элэгә.

Данир – беренче рәттә, сулдан беренче.

Сүз уңаеннан, *Татарстанның атказанган артисты Данир Сабировның көрәшче булганын белмәүчеләр бардыр әле. 2005 елда Муса Җәлил истәлегенә узучы көрәш турнирында катнашып, 3 нче урынны алуын яхшы хәтерли җырчы. Бу аның ир-атлар арасында тәүге тапкыр бил алышуы була. «Ул чакта беренче курста укый идем. Әллә ике спорт остасын оттым мин анда. Миңа – 18, көндәшләремә – 23–25 яшь... Муса Җәлил истәлегенә узучы көрәш ярышы – электән бик зур турнир инде ул. Финалда җиңелсәм дә, үземнән күпкә олырак көрәшчеләрне җиңеп, шундый зур турнирда өченче урында калуыма бик сөендем. Өстәвенә бүләккә микродулкынлы мич тә бирделәр», – дип сөйләгән иде Данир.*

31 гыйнвар | Чәршәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.05 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «КАЙДА СИН?» 16+
11.00, 00.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00, 00.25 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Азбука долголетия» 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я» 12+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.30 «БИЧАРАКАЙ» 16+
17.30 «Кызган казан» 6+
18.00 «Гаилә учагы» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Соотечественники» 16+
23.00 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
01.15 «Кәмит Җәвит» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Башваткыч» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 21.25 «Идрис Газиев тәкъдим итә» 16+
09.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
10.00 «Халкым минем» 12+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 04.20 «Сөйләшергә вакыт» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
18.20, 23.10 «Кәмит Җәвит» 16+
20.00, 00.15 «Гаилә учагы» 16+
03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «Большой дом» 16+
22.50 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Триггеры» 16+
00.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Летописи конца времен» 16+
01.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Все хотят летать» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
03.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Гори огнем!» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «МАСТЕР И МАРГАРИТА» 16+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.30 «Магия большого спорта» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.50, 18.30 Новости
07.05, 18.35, 21.45, 00.30 Все на Матч!
10.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
10.25 «Лучшие из лучших» 12+
11.25 Бокс. Bare Knuckle FC 16+
13.00 «Есть тема!»
14.20, 01.00 «Вид сверху» 12+
14.55 Прыжки в воду. BetBoom Кубок России
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. ЦСКА – «Торпедо»
22.40 «Чемпионы» 12+
01.30 «Что по спорту?» 12+
02.00 Лёгкая атлетика. Мировой тур в закрытых помещениях 6+
04.00 Дзюдо. Гран-при 12+

НТВ

04.50 «УГРО» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ШЕФ. МУЖСКАЯ РАБОТА» 16+
22.15 «ЗОЛОТОЕ ДНО» 16+
01.00 «МЕТЕОРИТ» 16+
03.25 «ВЕРСИЯ» 16+

ДОМАШНИЙ

07.20, 04.35 «Давай разведёмся!» 16+
08.20, 02.55 «Тест на отцовство» 16+
10.30, 23.20 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.35 «Порча» 16+
12.50, 01.35 «Знахарка» 16+
13.25, 02.05 «Верну любимого» 16+
14.00, 02.30 «Голоса ушедших душ» 16+
14.35 «СЛОВНО НЕ БЫЛО РАЗЛУКИ» 16+
19.00 «КОГДА СПАДЁТ ПЕЛЕНА» 16+
05.25 «6 кадров» 16+
05.35 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

07.00 «Сегодня утром». 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 00.40 «АПАЧИ» 12+
12.50, 18.50 «Специальный репортаж» 16+
13.25, 03.00 «ПСЕВДОНИМ «АЛБАНЕЦ»-2» 16+
15.00 Военные новости 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Секретные материалы» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.10 «713-Й ПРОСИТ ПОСАДКУ» 12+
02.10 «Зафронтовые разведчики» 16+
02.50 «Оружие Победы» 12+

1 февраль | Пәнҗешәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00, 04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
14.00 «Память сердца» 16+
14.15 «Азбука долголетия» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.30 «БИЧАРАКАЙ» 16+
17.30 «Точка опоры» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Погружение на 100» 12+
21.10 «Наши герои» 16+
23.00 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «СӨЮ КӨТӘ ЙӨРӘК» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00, 00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 04.20 «Кәмит Җәвит» 16+
09.30 «Гаилә учагы» 16+
10.00, 20.00 «Кызган казан» 6+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05 «Әниемнең җылы «кочагы» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
18.20, 23.10 «Сөйләшергә вакыт» 16+
21.25, 03.30 «Мизгелләр» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 Проект «Цивилизации» 12+
21.00 «Время»
22.00 «Большой дом» 16+
22.50 «Большая игра» 16+
00.00 «Ничего не бойся, кроме Бога» 0+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
01.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
02.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Хоккей не футбол» 16+
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Хоккей не футбол» 16+
03.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
04.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «МАСТЕР И МАРГАРИТА» 16+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Лига в лицах» 12+
06.30 «Вид сверху» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.50 Новости
07.05, 19.15, 21.30, 00.30 Все на Матч!
10.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
10.25 «Лучшие из лучших» 12+
11.25 Бокс. Bare Knuckle FC 16+
13.00 «Есть тема!»
14.20, 01.00 «Большой хоккей» 12+
14.55 Прыжки в воду. BetBoom Кубок России
17.00 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Салават Юлаев» – «Лада»
19.25 Футбол. Кубок равноправия. «Шанхай Шеньхуа» – «Аль-Духаиль»
22.25 Профессиональный бокс. Костя Цзю 16+
01.30 «Что по спорту?» 12+
02.00 Бильярд. «BetBoom Суперлига». Финал 0+
04.00 Дартс. PARI Международная лига. Тур 1 0+

НТВ

04.50 «УГРО» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ШЕФ. МУЖСКАЯ РАБОТА» 16+
22.15 «ЗОЛОТОЕ ДНО» 16+
01.00 «Поздняков» 16+
01.20 «Мы и наука. Наука и мы» 12+
02.20 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+
03.20 «ВЕРСИЯ» 16+

ДОМАШНИЙ

07.20, 04.15 «Давай разведёмся!» 16+
08.20, 02.35 «Тест на отцовство» 16+
10.30, 23.10 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.20 «Порча» 16+
12.55, 01.15 «Знахарка» 16+
13.30, 01.40 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.10 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «ВСЁ РАВНО ТЫ МОЯ» 16+
19.00 «БЕДНАЯ РОДСТВЕННИЦА» 16+
05.05 «6 кадров» 16+
05.35 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15 «Открытый эфир» 16+
11.00 «УЛЬЗАНА» 12+
13.25, 02.30 «ПСЕВДОНИМ «АЛБАНЕЦ»-2» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Код доступа» 12+
21.00 «Открытый эфир» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «СОЛДАТЫ» 12+
01.25 «Автомобили Второй мировой войны» 16+
02.05 «Хроника Победы» 16+

2 февраль | Җомга

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Вести ПФО»
09.15 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.15 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР» 16+
11.00 «Нәсыйхәт» 16+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00 «Ком сәгате» 16+
13.00 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 16+
14.15 «Наши герои» 16+
14.45, 01.00 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.30 «БИЧАРАКАЙ» 16+
17.30 «Кто мы татары?» 12+
18.00 «Татар халык җырлары» 0+
19.00 «Болгар радиосы» концерты 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Юлчы» 16+
22.10 «Сөйләшергә вакыт» 16+
23.10 «КВН РТ-2024» 16+
23.40 «ПРОСТО САША» 12+
01.25 «Фолиант в столетнем переплете» 16+
01.40 «ЕРАКТАГЫ ЙОЛДЫЗЫМ» 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05 «Манзара» 16+
08.00, 19.10 «Җырлый Руслан Дәминов» 6+
08.30, 18.20, 23.10, 04.20 «Ком сәгате» 16+
09.30, 16.30, 00.15 «Нәсыйхәт» 16+
10.00, 20.30, 02.00 «Заман көзгесе» 6+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 01.05, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 21.55 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
20.00 «Ватандашлар» 16+
21.25 «Кто мы татары?» 12+
22.15, 02.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
18.40 «Человек и закон» 16+
19.45 «Поле чудес» 16+
21.00 «Время»
21.45 «Голос» 12+
23.30 «Матадор» 18+
00.30 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Судьба человека» 12+
16.30 «Прямой эфир» 16+
21.30 «Ну-ка, все вместе! Хором!» 12+
23.55 Первые 100 лет. Юбилей киностудии «Мосфильм»
02.25 «Мосфильм» на ветрах истории» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Третий тайм» 12+
06.30 «Большой хоккей» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.50 Новости
07.05, 16.00, 21.45, 00.30 Все на Матч!
10.05 «Небесная грация» 0+
10.25 «Лучшие из лучших» 12+
11.25 Профессиональный бокс 16+
12.35 «Лица страны» 12+
13.00 «Есть тема!»
14.20, 01.00 «Формула-1. Гаснут огни» 12+
14.55 Прыжки в воду. BetBoom Кубок России
16.30 Футбол. Winline Зимний кубок РПЛ. «Ростов» – «Шабаб Аль-Ахли»
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. ЦСКА – СКА
22.25 Футбол. Чемпионат Германии
01.30 «Что по спорту?» 12+
02.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Уралмаш» – «Пари Нижний Новгород» 6+
04.00 Прыжки в воду. BetBoom Кубок России 0+
05.00 Бокс. Bare Knuckle FC

НТВ

04.50 «УГРО» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «Прошу, прости!» 16+
17.55 «Жди меня» 12+
20.00 «ШЕФ. МУЖСКАЯ РАБОТА» 16+
00.00 «Своя правда» 16+
01.55 «Квартирный вопрос» 0+
02.50 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+
03.20 «ВЕРСИЯ» 16+

ДОМАШНИЙ

07.20, 04.15 «Давай разведёмся!» 16+
08.20, 02.35 «Тест на отцовство» 16+
10.30, 23.10 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.20 «Порча» 16+
12.55, 01.15 «Знахарка» 16+
13.30, 01.40 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.10 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «ПО ТОНКОМУ ЛЬДУ» 16+
19.00 «Я ТЕБЯ НЕ ОТПУЩУ» 16+
05.05 «6 кадров» 16+
05.35 «По делам несовершеннолетних» 16+
06.25 «ПРИДУМАННОЕ СЧАСТЬЕ» 16+

ЗВЕЗДА

06.15 «СОЛДАТЫ» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.25, 21.20 «Специальный репортаж» 16+
09.40 «РАЗМАХ КРЫЛЬЕВ» 12+
11.40, 13.25, 15.05 «Забытые войны России» 16+
15.00 Военные новости 16+
17.15 «Сталинград. Ни шагу назад!» 16+
19.40 «Загадки века» 12+
20.30 «Скрытые угрозы» 16+
22.00 «Здравствуйте, товарищи!» 16+
23.30 «Музыка+» 12+
00.55 «ГАРАЖ» 12+
02.30 «ЛИХА БЕДА НАЧАЛО» 12+
03.45 «БЛИЗНЕЦЫ» 6+

3 февраль | Шимбә

ТАТАРСТАН

08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
07.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 16+
09.00 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00 «Туган авылым» 12+
11.30, 01.00 «Музыкальный майдан» 16+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
13.30 «Гаилә учагы» 16+
14.00 «Язлар» 12+
14.45 Хоккей. КХЛ Чемпионаты. «Трактор» – «Ак барс» 6+
17.30 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
18.00, 04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
19.30 Новости в субботу 16+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
21.30 Новости в субботу 16+
22.00 «РАЗВОД ПО-ФРАНЦУЗСКИ» 12+
23.30 «НАЧАТЬ С НУЛЯ» 16+
01.30 «ЯЗМЫШЛАРДАН УЗМЫШ ЮК ИКӘН» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 02.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
07.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 16+
09.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00, 18.15, 03.00 «Башваткыч» 12+
12.05, 19.05, 03.50 «Җырлыйк әле!» 12+
13.30, 00.25 «Язмыш юллары» 16+
17.15 «Калеб» 6+
17.45, 05.05 «Халкым минем» 12+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 Татарстанның халык артисты, Россиянең атказанган артисты Мирсәет Сөнгатуллинның 70 яшьлек юбилей кичәсе 12+
22.30 М.Гали. «Мөһаҗирләр». Минзәлә татар дәүләт драма театры спектакле 16+
01.35 «Идрис Газиев тәкъдим итә» 16+
04.40 «Заман көзгесе» 6+
05.30 «Нәсыйхәт» 16+

1 КАНАЛ

06.00 «Доброе утро. Суббота»
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00, 12.00 Новости
10.15 «Наше всё» 12+
11.05 «ПроУют» 0+
12.15 «Поехали!» 12+
13.10 «СВОЙ СРЕДИ ЧУЖИХ, ЧУЖОЙ СРЕДИ СВОИХ» 12+
15.10 «ЭКИПАЖ» 12+
18.00 Вечерние новости
18.20 «Я люблю мою страну» 0+
19.20 «Эксклюзив» 16+
20.05 «Кто хочет стать миллионером?» 12+
21.00 «Время»
21.35 «Сегодня вечером» 16+
23.00 «ПОДЕЛЬНИКИ» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Триггеры» 16+
02.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Кот Шрёдингера» 16+
03.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
04.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
05.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Вести. Местное время
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.50 «В кругу друзей»
12.50 «Доктор Мясников» 12+
14.50 «Весёлья час» 16+
17.50 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ЧУЖОЙ РЕБЁНОК» 16+
00.40 «МАСТЕР И МАРГАРИТА» 16+
02.35 «ДЕРЕВЕНСКАЯ ИСТОРИЯ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Бокс. Bare Knuckle FC
08.00, 08.30, 13.10 Новости
08.05, 17.00, 19.30, 22.00, 01.00 Все на Матч!
08.35 Лыжные гонки. Альфа-Банк Кубок России. Спринт
13.15 «Дуэль. Финал» 12+
14.35 Лёгкая атлетика. Международные соревнования «Русская зима»
17.25 Футбол. Чемпионат Германии. «Бавария» – «Боруссия»
19.55 Футбол. Чемпионат Италии. «Фрозиноне» – «Милан»
22.30 Профессиональный бокс. IBA Champions Night
01.45 Прыжки в воду. BetBoom Кубок России 0+
03.00 Смешанные единоборства. UFC

НТВ

04.50 «УГРО» 16+
06.20 «Жди меня» 12+
07.20 «Смотр» 0+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «Поедем, поедим!» 16+
09.20 «Едим дома» 0+
10.20 «Главная дорога» 16+
11.00 «Живая еда» 12+
12.00 «Квартирный вопрос» 0+
13.00 «Основано на реальных событиях» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «ЧП. Расследование» 16+
17.00 «Следствие вели…» 16+
19.00 «Центральное телевидение»
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.20 «Секрет на миллион» 16+
23.25 «Международная пилорама» 18+
00.10 «Захар Прилепин. Уроки русского» 12+
00.50 «Квартирник НТВ у Маргулиса». Вокруг спектакля «Саундтрек» 16+
02.15 «Дачный ответ» 0+
03.05 «ВЕРСИЯ» 16+

ДОМАШНИЙ

10.25 «Уютное утро» 16+
10.55, 03.40 «КУРОРТ ЦВЕТА ХАКИ» 16+
19.00 «ДОБРОТА» 16+
22.40 «НЕ ОТРЕКАЮТСЯ ЛЮБЯ» 16+
02.10 «Знать будущее. Жизнь после Ванги» 16+

ЗВЕЗДА

05.05 «КОРОЛЬ ДРОЗДОБОРОД» 6+
06.10 «ЦАРЕВИЧ ПРОША» 6+
08.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
08.15 «Морской бой» 6+
09.15, 02.55 «ТРЕМБИТА» 12+
11.10 «Легенды музыки» 12+
11.40 «СССР. Знак качества» 12+
12.30 «Не факт!» 12+
13.15 «Легенды кино» 12+
14.00 «Главный день» 16+
14.50 «Время героев» 16+
15.10, 19.25 «ОСВОБОЖДЕНИЕ» 12+
01.30 «ДВА ФЕДОРА» 12+
04.25 «ЛИХА БЕДА НАЧАЛО» 12+

4 февраль | Якшәмбе

ТАТАРСТАН

08.00 Местное время. Воскресенье

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 Марат Мухин хитларыннан к06.00 «Пар алма» 16+
08.00, 13.00 «Адымнар» 16+
08.30 Мультфильмы 6+
08.45 «Әти һәм мин» 0+
09.15 «Тамчы-шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 0+
10.15 «Кызган казан» 6+
11.00, 03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество» 16+
13.30 «Погружение на 100» 12+
13.40 «Татар сүзе» 12+
14.00 «Наша Республика – наше дело» 16+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
16.00 «Ком сәгате» 16+
17.00 «Видеоспорт» 16+
17.30 «Соотечественники» 16+
18.00 «Башваткыч» 12+
19.00, 22.00 «Семь дней» 16+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты 16+
21.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
23.00 «ЖМОТ» 16+
00.30 «ЯЗМЫШЛАРДАН УЗМЫШ ЮК ИКӘН» 16+
02.05 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+
05.50 Татарстан хәбәрләре 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Заман көзгесе» 6+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять»
07.00 «Адымнар» 16+
07.30 «Кто мы татары?» 12+
08.00 «Әйдә, дустым, уйнат гармуныңны» 16+
09.00, 03.40 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
10.00 «Кызган казан» 16+
10.30 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05, 00.40 «Яшьләр тукталышы» 6+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00, 04.35 «Гаилә учагы» 16+
13.30 «Фәрештә түгел» 16+
15.40 Х.Ибраһимов. «Жизнәкәй». Уфа «Нур» татар дәүләт драма театры спектакле 16+
17.15, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит» 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате» 16+
20.00 «Семь дней» 16+
21.50 З.Хәким. «Мин төш күрдем». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
01.05 «Манзара» 16+
02.45 «Шаян хәлләр» 16+
03.15 «Әдәби хәзинә» 6+
05.00 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

06.00, 10.00, 12.00 Новости
06.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
06.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.40 «Часовой» 12+
08.10 «Здоровье» 16+
09.20 «Мечталлион» 12+
09.40 «Непутевые заметки» 12+
10.15 «Жизнь своих» 12+
11.05 «Повара на колесах» 12+
12.15 «Видели видео?» 0+
14.00 Фильм «Горячий снег» 12+
16.00 «Мосфильм». Рождение легенды» 12+
18.00 Вечерние новости
19.00 «Лучше всех!» 0+
21.00 «Время»
23.00 «КОНТЕЙНЕР» 16+
00.50 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

06.10, 01.30 «СЮРПРИЗ ДЛЯ ЛЮБИМОГО» 12+
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома»
09.25 «Утренняя почта»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 17.00 Вести
12.00 «Большие перемены»
13.00 «БЕЗ ЛЮБВИ» 12+
17.50 «Песни от всей души» 12+
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «География спорта» 12+
06.30 «Магия большого спорта» 12+
07.00, 08.30 Новости
07.05, 13.30, 15.55, 19.30, 22.00, 00.45 Все на Матч!
08.35 «Команда МАТЧ» 0+
08.40 Лыжные гонки. Альфа-Банк Кубок России. Масс-старт.
11.25 «ТРИУМФ» 12+
13.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. ЦСКА – УНИКС
16.25 Футбол. Кубок равноправия. «Сантос» – «Шанхай Шеньхуа»
18.30 Смешанные единоборства. UFC 16+
19.55 Футбол. Чемпионат Италии.
01.30 Прыжки в воду. BetBoom Кубок России 0+
03.00 «Вы это видели» 12+
04.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Руна» – «Локомотив-Кубань» 6+

НТВ

04.50 «УГРО» 16+
06.30 «Центральное телевидение» 16+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача» 16+
11.00 «Чудо техники» 12+
12.00 «Дачный ответ» 0+
13.00 «НашПотребНадзор» 16+
14.05 «Однажды…» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «Человек в праве» 16+
17.00 «Следствие вели…» 16+
18.00 «Новые русские сенсации» 16+
19.00 «Итоги недели»
20.20 «ЦЕРБЕР» 16+
00.25 «Звезды сошлись» 16+
02.00 «ВЕРСИЯ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.50 «НЕ ОТРЕКАЮТСЯ ЛЮБЯ» 16+
10.40 «Пять ужинов» 16+
10.55 «ПРО ВЕРУ» 16+
19.00 «ДОБРОТА» 16+
22.40 «ПРИДУМАННОЕ СЧАСТЬЕ» 16+
02.25 «КУРОРТ ЦВЕТА ХАКИ» 16+
05.40 «Знать будущее. Жизнь после Ванги» 16+

ЗВЕЗДА

05.35 «АТЫ-БАТЫ, ШЛИ СОЛДАТЫ…» 12+
07.10 «КОНТРУДАР» 12+
09.00 «Новости недели» 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.40 «Легенды армии» 12+
11.30 «Моторы и колеса» 12+
12.20 «Война миров» 16+
13.10 «Код доступа» 12+
14.00 «Скрытые угрозы» 16+
14.50 «Секретные материалы» 16+
15.40 «Загадки века» 12+
16.30 «Улика из прошлого» 16+
17.20 «Специальный репортаж» 16+
18.00 Главное 16+
20.00 «Легенды советского сыска» 16+
22.35 «Москва фронту» 16+
23.00 «Фетисов» 12+
23.45 «АЛЛЕГРО С ОГНЕМ» 12+
01.35 «ПО ДАННЫМ УГОЛОВНОГО РОЗЫСКА…» 12+
02.45 «Автомобили Второй мировой войны» 16+
03.25 «Забытые войны России» 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм һөнәри эшчәнлектәге казанышлары өчен Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең «Фармэксперт» төбәк фәни-тәҗрибә үзәге җитәкчесе **Садыйкова** Разия Габделәхәт кызы, җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдәге, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары өчен Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Алабуга районы буенча бүлеге башлыгы, полиция полковнигы **Пономарев** Юрий Николаевич **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Казан шәһәренең «М.Н. Садыйков исемендәге 7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең эндоурология шәһәр үзәге җитәкчесе – табиб-урологы **Перчаткин** Владимир Александровичка **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе оператив штаб аппараты өлкән офицеры (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы кадры буларак калдырып, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенә вакытлыча беркетелгән), полиция подполковнигы **Билалов** Илһам Гыйльфан улына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының шәхси состав белән эшләү идарәсе әхлакый-психологик тәэмин итү бүлеге башлыгы урынбасары, полиция полковнигы **Сюткин** Андрей Владимировичка, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы икътисадый куркынычсызлык һәм коррупциягә каршы көрәшү идарәсенең мәгълүмати-телекоммуникация технологияләрен кулланып кылынган җинаятьләргә һәм ялган акча сугуга каршы көрәшү бүлеге башлыгы, полиция подполковнигы **Фомин** Павел Анатольевичка, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы идарәсе башлыгы урынбасары – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама районы буенча идарәсе тикшерү идарәсе башлыгы, юстиция подполковнигы **Хафизов** Рөстәм Расих улына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы эш башкару һәм режим идарәсе башлыгы урынбасары – бүлек (режим һәм дәүләт серен саклау бүлеге) башлыгы, эчке хезмәт полковнигы **Еникиев** Руслан Равил улына **«Татарстан Республикасы буенча атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Дәүләт янгынга каршы көрәшү хезмәте янгынга каршы көрәшү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча шартнамәле бүлекчәләре идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Әлмәт филиалы Дәүләт янгынга каршы көрәшү хезмәте федераль янгынга каршы көрәшү хезмәте отряды башлыгы **Әхсәнов** Нәсим Нәсих улына, Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше идарәсенең Кама Тамагы һәм Тәтеш муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше районара бүлекчәсе башлыгы, эчке хезмәт подполковнигы **Камбиев** Илсур Илгиз улына, «Татарстан Республикасы Граждан оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасы Эзләү-коткару хезмәте» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесенең 2 номерлы зона эзләү-коткару отряды (Казан) коткаручысы **Шинкевич** Олег Васильевичка **«Татарстан Республикасының атказанган коткаручысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары өчен Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе хезмәткәрләре: Чаллы шәһәре буенча тикшерү бүлеге җитәкчесе, юстиция полковнигы **Викентьев** Евгений Игоревичка, идарә җитәкчесенең өлкән ярдәмчесе (физик яктан саклануны оештыру мәсьәләләре буенча), юстиция полковнигы **Матренин** Алексей Алексеевичка, аеруча мөһим (чит ил гражданнары яисә гражданлыгы булмаган затлар тарафыннан кылынган җинаятьләр турында) эшләрне тикшерү буенча алтынчы бүлекнең аеруча мөһим эшләр тикшерүчесе, юстиция майоры **Хәсәншина** Тәслия Фәрит кызына, беренче контроль-тикшерү бүлеге җитәкчесе урынбасары, юстиция полковнигы **Хөснетдинов** Рамил Рөстәм улына **«Татарстан Республикасының атказанган юристы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Аксубай районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең Тимошкино ветеринария участогы мөдире – ветеринария табибы **Алимбәков** Фәрхәт Сәетгәрәй улына, «Чишмә» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең баш ветеринария табибы (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Әхмәтов** Илназ Ирек улына, «Кайбыч районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе ветеринария табибы **Габдуллин** Наил Галимулла улына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе Ветеринария иминлеге һәм дәүләт күзәтчелеге Чаллы территориаль бүлеге башлыгы **Мифтахов** Фәнис Хасият улына, «Чүпрәле районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең район ветеринария лабораториясе лаборанты **Хубахова** Галина Владимировнага **«Татарстан Республикасының атказанган ветеринария табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

ЯШӘҮ БЕЛӘН ҮЛЕМ АРАСЫНДА

27 ГЫЙНВАРДА ЛЕНИНГРАД КАМАЛЫШЫ ӨЗЕЛҮГӘ 80 ЕЛ ТУЛА

Ленинград камалышы – Бөек Ватан сугышы тарихында иң озакка сузылган һәм иң фаҗигале вакыйгаларның берсе. Герой-шәһәр, калкан булып, яуга күтәрелә. Тәп-төгәл 871 көн (1941 елның 8 сентябреннән 1944 елның 27 гыйнварына кадәр) дәвам иткән бу мәхшәр 2 миллионнан артык кешенең гомерен өзә.

vk.com

Ленинград камалышын кичерүчеләр тәүлегенә нибары 125 грамм ипи биргәнне хәтерли.

Тормыш юлы

1941 елның 20 ноябрендә Ленинградта ачлык башлана. Дошман Ладога күле тирәсенә килеп җитә, Ленинград округында урнашкан 200 азык-төлек складын юк итә, бу барлык резервның 52 проценты була.

1941 елның 22 ноябрендә Ладога күле бозы аша Ленинградка ярдәм килә. Боз өстеннән үткән әлеге юл «Тормыш юлы» дип атала. Аның аша 1941–1942 ел кышында гына да шәһәргә 360 мең тонна йөк китерелә, барлыгы 1,4 млн кеше эвакуацияләнә. Ладога күле төбеннән махсус торба үткәрелә, шәһәргә нефть продуктлары җибәрелә, ә 1942 елда электр кабеле сузыла.

Якташлар

1941 елның 8 сентябреннән 1944 елның 27 декабренә кадәр Нева елгасы буендагы шәһәрне саклап, 45 меңгә якын якташыбыз һәлак була. Бу хакта безгә «Хәрби дан клубы» ассоциациясе җитәкчесе Михаил Черепанов сөйләде.

– Безнең якташлар блокаданы өзү операциясендә инде 1942 елның гыйнварыннан ук Бөек Новгород шәһәренең фаҗигале язмышы белән телгә кергән Мясной Бор станциясендә катнаша башлый. Ул вакытта «Очкын», «Гыйнвар гөрелтесе», «Нева-2» операцияләрендә катнашучылар Төньяк башкалага ярдәмгә ашыга. Соңгысы – Ленинград – Новгород һөҗүм операциясе 1944 елның 14 гыйварыннан 30ына кадәр Ленинград һәм Волхов фронтлары ярдәмендә үткәрелә. Аларга Балтыйк флоты, Ладога хәрби флотилиясе һәм авиациясе кушыла. Камалышны тулысынча өзгән көннәрдә,1944 елның 26 һәм 27 гыйнварында гына да көрәш кырында һәлак булган, төрле яралардан үлгән якташларыбызның саны 94кә тула.

«Татар башкаласы исән калсын өчен, мин рус башкаласын саклыйм». Бу сүзләрне фронтовик шагыйрь Гадел Кутуй 1942 елда яза. Ул әсәрләрендә Ленинградны саклаганда татарларның нинди батырлык күрсәткәнен сурәтли. Бу елларда Төньяк башкалада хәтта татар телендә «Ил сагында» дигән газета да нәшер ителә. Ә фашистлар, әсирлеккә төшәргә чакырып, камалышта калган шәһәр өстенә яңалиф белән язылган листовкалар ыргыталар.

– Ленинград блокадасында күпме кеше һәлак булганын без бары тик XXI гасырда гына белә алдык, – ди Михаил Черепанов. – Аңа кадәр бу хактагы документлар «яшерен» тамгасы белән сакланды. Күз алдына китерү дә авыр: 871 көн эчендә ачлыктан, салкыннан һәм бомбалар шартлаудан бер миллионнан артык җирле халык һәлак булган. Төньяк башкаланы азат итү өчен көрәшкән Кызыл Армия сугышчыларының да саны шуннан ким түгел.

Россия Оборона министрлыгы архивларыннан, хәрби комиссариатлар картотекаларыннан, Татарстан эзләнү отрядлары экспедицияләренең Ленинград һәм Бөек Новгород өлкәләрендә табылган мәгълүматларыннан күренгәнчә, камалыш елларында Ленинград өлкәсендә 21469 татарстанлы һәлак булган. Шуларның 3947се Санкт-Петербург зиратларында җирләнгән. Моннан тыш, 12914 сугышчы бүгенге Бөек Новгород җирендә башын салган.

Ни кызганыч, бу солдатларның бер өлеше әлегә кадәр Ватан өчен сугышта һәлак булган дип танылмый. Бүген рәсми төстә бары тик 34405 якташыбыз гына Ленинград өчен сугышларда һәлак булган дип санала. Анысы да безнең эшче төркемнең тырышлыгы, эзләнүләре ярдәмендә генә ачыкланды.

Җиңү

1944 елның гыйнварында Ленинград блокадасын өзү буенча зур күләмле операция үткәрелә. Фронтның киңлеге 45 километрга җитә. Совет гаскәрләре, тәүлегенә 3–3,5 км ара үтеп, дошманны 60 чакрымга чигенергә мәҗбүр итә. Ленинград камалышы өзелә. Калинин һәм Ленинград өлкәләре тулаем дошманнан азат ителә.

Тарих китапларыннан билгеле булганча, Гитлер 1942 елның 8 августында ук шәһәрне алу көненә багышланган тантана уздырырга ниятли. Ләкин хыялы тормышка ашмый. Ә шәһәрдә бу көнне чынлап та зур концерт була. Ләкин дошманныкы түгел, ә филармония залында Шостаковичның 7 нче симфониясе яңгырый.

Хәтер

Вафирә апа Вәлитова сөйләгәннәрдән:

– 1942 елның көзендә безне Финляндия чигеннән Ленинградка китереп бушаттылар. Ачлыктан хәлсезләнгән идек, ашарга бернәрсә юк. 125 грамм ипи бирәләр, анысы да тачка, пычакны суга манып кисәләр иде. Ике айга бер тапкыр 400 грамм ярма бирәләр иде кебек, анысы эләксә әләгә, эләкмәсә – юк. Азык-төлек карточкаларын югалтучылар да күп булды. Үзем дә бервакыт алып кайтканда икмәкне урлаттым…

Безнең өчен кайгырып, әтиебез үзе ачлыктан үлеп китте. Бик яхшы хәтерлим: 1942 елның 14 гыйнвары иде бу. Без аның мәетен күрше бүлмәгә чыгарып куйдык. Анда тагын 7–8 мәет ята. Үлүчеләр күп, аларны алып китәргә, җирләргә өлгермиләр. Күршебездә үлгән әтиләрен пешереп ашаган гаиләне төрмәгә алып киткәннәр, дигән сүзләр дә ишеттек. Сугыш безне вакытыннан алда олыгайтты, курыкмаска өйрәтте, яңадан-яңа кайгы-хәсрәтләр биреп чыныктырды. Без әни белән өч бала: мин, сеңлем Сабира, энем Габдулла калдык. Әнинең дә хәле яхшы түгел иде. «Әни, без кайчан үләбез?» – дип сорыйм әнидән. Ул исә: «Кызым, үлүен үләрбез, тик бер туйганчы ипи ашыйсы иде», – ди. Әти үлеменә бер ай булдымы икән, әнигә ипи ашатырга теләп, иртәнге 4тә кибеткә киттем. Ипи алып кайттым. Әни мин киткәндә йоклап калган иде. Кайтсам, үлгән, ипине ашата алмадым. Ул төнне энем, сеңлем белән әнине кочаклап йокладык. Икенче көнне Ачасырдан килгән Хәрирә апа белән Акъегеттән Газизә апа, әнине юып, кәфенләп, балконга чыгарып куйдылар. Бу 16 февраль иде. Әни балконда озак ятты, мәет җыеп йөрүчеләрнең безнең әнигә чиратлы җитмәде. Чанага салып, әнине зиратка үзебез алып киттек. Мәетен шунда калдырып кайттык. Иртәгесе көнне тагын әниебезне карарга бардык. Ләкин ул юк иде инде…

Зинаида Бушуева сөйләгәннәрдән:

– Мин 1932 елда Ленинградта тудым. Әтием хәрби кеше иде, әнием заводта эшләде. Сугыш алдыннан әтиемне Выборгка күчерделәр. Шулай итеп, гаилә белән Юховец утравына күчендек, ә берничә айдан сугыш башланды. Күп вакыт үтмәде, әтиебез һәлак булды. Без утрауда кышкы киемнәрсез һәм бернинди азык-төлексез калдык. Әни, туң җирне казып, кырдан үлән, бәрәңге алып кайткалады. Кешеләр, ачлыкка түзә алмыйча, урамда барган җирдән егылып үләләр иде. Мондый хәлне мин күп тапкырлар үз күзләрем белән күрдем. Сеңлем дә үлеп китте. Тагын бер бик куркыныч хәл күз алдымда тора. Күрше апаның бәләкәй генә эте бар иде. Башта аны кырын-кырын күзәткәләп, караштыргалап кына йөрделәр. Соңыннан ни теләгәннәрен ачыктан-ачык әйтә башладылар. Әмма күрше апа ул этне шулкадәр ярата иде ки, хәтта аның белән бергә үләргә дә әзер иде. Берничә көннән ачлыктан ыргыйланган халык аның фатирына бәреп керде, этне караватаягына бәйләп куйдылар. Утын пүләне белән бер тапкыр башына тондыру җитте, ул чинап алды да тынып калды. Мин исә бер почмакта, аш исенә түзә алмыйча, еладым да еладым. Инде этне дә җәлләми идем. Бары тик ашыйсы килүгә генә чик-чама юк иде.

Безне Ладога күле аша эвакуацияләделәр. Башта Краснодар краена, аннан Казанга китерделәр. Ленинградтагы ачлык турында беркайда да сөйләргә ярамады. Мин мәктәпкә барганда, әнием эшкә урнашканда, безне бу хакта кат-кат кисәттеләр.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Белешмә

1941 елның 23 июненнән Ленинград шәһәре һәм өлкәсеннән 300 мең кеше Совет Армиясенә алына, хәрәкәттәге армия һәм флот сафларына баса. Шуңа өстәп, тагын 250 мең кеше фронтка озатыла. 135 мең ленинградлы халык ополчениесе дивизияләренә кушыла. Шәһәрнең һәр кешесе диярлек 27 мең км озынлыгындагы окоплар, танкларга каршы 625 км тирәсе чокырлар казуда, 5 мең дот һәм дзотлар төзүдә, танкларга каршы 49 мең тимербетон багана урнаштыруда катнаша, шәһәрне саклауда катгый чаралар күрә.

Сан

Камалыш чорында дошман шәһәргә **150** мең снаряд, **107** мең тирәсе авиация бомбасы ата. Фашистлар Ленинград каласын 1942 елда – **390**, 1943 елда **2490** тапкыр көчле артиллерия һәм авиация утына тота, аны җир белән тигезләргә омтыла.

Ләйсән Газизова

УТЫНСЫЗ ТӨТЕН ЧЫКМЫЙ

Чистай районының Татар Баганасы авылында пычкы тавышлары тынып тормый: утынны кисәләр, ярып, әрдәнәгә өяләр. Йортларга газ керсә дә, утынның һәрвакыт кирәге чыгып тора. Халык ни өчен урманнан ерагаймаган? «ВТ» хәбәрчесе авыл халкының хәлен, агач әзерләү тәртибен, бер арба утынның күпмегә төшүен белеште.

Шөгыль

Татар Баганасы җирлегендә 520ләп кеше яши. Монда мәктәп, бакча, клуб бар. Урман кул сузымында гына. Авыл җирлеге башлыгы Рафис Җәббаров әйтүенчә, авыл халкы, кирәк-яракка дип, рөхсәт алып, урман кисә. Бу эш белән күбрәк пенсия яшендәгеләр, эш урыны булмаганнар шөгыльләнә. Утын ярдыру цехы тотучы шәхси эшмәкәр дә бар.

– Кышын урманда кар ерып утын кисүче юк. Җәйкөз алып кайткан чималны әзерлиләр. Кемдер утынны кул белән, кемдер махсус җайланма белән яра, – ди Рафис Җәббаров.

Алсу һәм Илнур Зиннуровлар урманга 15 ел йөри икән инде. Рәхәттән түгел, утын кирәк булганга. Алсу мәктәптә идән юа, ире котельняда эшли. Терлек асрап көн күрәләр. Утын сатып алмас өчен, урманга барырга да вакыт табалар. Кышка запас булгач, күңелләре тыныч.

– Урман кисү – авыр хезмәт. Ботагын җыярга, яндырырга кирәк, артыннан җыештырып куясы. Җәй көне кисәбез, көзен ярабыз. Ирем белән икәү бергә кисәбез һәм төйибез. Авыр булса да, түзәбез инде. Кышын мунчага 1–2 трактор утын китә, – ди Алсу Зиннурова.

Алсу әйтүенчә, урманны җыештырмасаң, чытырманлыкка әйләнәчәк, черек агачлар каплаячак. Ә алар урман чистартуга үз өлешен кертә. Законны бозмыйлар. Бар да документ буенча эшләнә. «Кисмәгез, дисәләр, кисмәячәкбез», – ди ул.

Рафис Гатин Чистайда яши, ләкин туган нигезенә әтисенең хәлен белешергә еш кайта. Үзе дә лаеклы ялда инде. Җәен авылда умартачылык белән шөгыльләнә. Кыш көне остаханәсендә рамнар, оялар ясый. Аны җылытырга кирәк. Шәһәрдә мунчасына 10–12 кубометр утын китә. Гатиннарның чыгымнары шундыйрак. Үзең кисү сатып алуга караганда күпкә арзанга чыга, ди гаилә башлыгы.

– Акчаны исә нинди агач кисүгә, аның сортына карап түлибез, – ди Рафис Гатин. – Башта министрлыкка гариза язабыз. Рөхсәт биргәч, урманчылыкка боерык килә. Шуннан соң кисү өчен диләнке билгеләнә. Нинди агачлар бирелсә, шуны кисәсең. Җәй көне бер мәртәбә әзерләп куям да, шул җитә.

Сиксәнгә җитүчеләр арасында да урман кисүчеләр бар. Алар утынның кадерен аңлый. Урманнан көч алып, рәхмәтле булып яши.

– Элек утын кисү эше күпкә катлаулырак иде. Пычкысы кабынмыйча интектерә иде. Хәзергеләре яхшы кабына. Без утынны мунчага дип әзерлибез. Сатып аласы килми. 1 кубометр утын бәясе – 2–3 мең сум. Ә болай 8–9 мең сум түлибез. Шундый мөмкинлек биргән өчен министрлыккка рәхмәт, – ди 74 яшьлек Кирам Галимов.

Сыңар кул көче

Үзең иренәсең икән, Ривальгә куш! 50 яшьлек Риваль Хөсәенов сыңар кулы белән авыл халкының утынын яра. Рекорд та куйганы бар икән. Бер көндә ике «КамАЗ» арбасы утын ярган! Берьюлы 19 кубометр утын яру җиңел түгел, билгеле. Арыса да, кулына авырлык килмәгән.

– Эш башлаганда баштагы өч көне кыен була. Бер кызып киткәч, авырлыгын сизмим. Утынны 10 еллап ярам инде. Бик күп кешегә булыштым. Әле салкында өйдә тордым. Менә күршем Рәмис чакырды, аңа керермен, – ди оптимист Риваль.

Кулын 19 яшьтә пычкы белән өздергән ул. Эшләгәндә иң кирәге уңы бит әле. Тормышка яраклашу бик авыр булса да, әкренләп барысына да ияләшкән. Өр-яңадан тормыш башлаган, кыскасы. Хатыны Людмила белән өч бала үстерәләр. Гаилә башлыгы зарлануны белми. Телендә шушы сүзләр: «Тырышам, яшим һәм бар да яхшы булачак».

Күпме утын тиеш?

Авыл халкының шөгыле, агач кисү тәртибе, урман фәлсәфәсе турында Биләр урманчылыгы башлыгы Рамил Нуруллин белән сөйләштек.

– Бу авылда урманнан ерагайдылар дип әйтеп булмый. Авыл кешесе тик ятарга өйрәнмәгән. Районда Татар Баганасы, Чулпан авылы халкы урманны коры-сарыдан чистартырга булыша. Арада шул агачтан утын әзерләп сатучылар да бар, – ди Рамил Нуруллин. – Кипкән агач, ботакларны күпме кирәк, шуның кадәр җыярга ярый. Көчле җил, давыл-буран яки кирәгеннән артык кар яву нәтиҗәсендә җиргә сынып төшкән агачлар бу.

Кешегә елга бер мәртәбә кирәк-ярак өчен 20 куб метр агач кисәргә рөхсәт ителә. Агач түләп алына, тик аны сатарга ярамый. Авыл халкы бу мөмкинлектән дә файдалана. Газ бәясе күтәрелә тора, мичкә ягасыңмы, шашлык пешерәсеңме – утын һәрвакыт кирәк.

Сәрия МИФТАХОВА

«АВИТО»ДА УТЫН БӘЯСЕ

Бер кечкенә капчык (12–15 данә) >	**100** сум
1 сеткасы >	**350** сум
1 кубометры >	**2000–2500** сум
Каенның 1 кубометры >	**2200** сум
Усакныкы >	**2000** сум
Бер арба (4 кубометр) >	**10000** сум

Белеп торыгыз!

Рөхсәтсез урман кискән кискән гражданнарга административ штраф күләме – **3–4 мең** сум, вазыйфаи затларга – **20–40 мең** сум, юридик затларга **200–300 мең** сум. Моннан тыш, агачның токымына һәм аның үсү урынына карап та зыянны капларга туры киләчәк.
5 мең сум һәм аннан да күбрәк зыян китерелгән очракта Россия Федерациясе Җинаять кодексы буенча җинаять җаваплылыгы каралган.

УРМАН КИСҮ ТӘРТИБЕ

Татарстан Урман хуҗалыгы министрлыгының матбугат хезмәте:

«Татарстанда урманнардан файдалану турында»гы Закон нигезендә, гражданнар, кирәк булганда, йорт һәм ишегалды корылмалары төзү өчен 25 елга бер тапкыр – 100 кубометрга кадәр агач, 10 елга бер тапкыр йорт һәм каралты-кураларны төзекләндерү өчен – 50 кубометрга һәм елына бер тапкыр утын өчен 20 куб. метрга кадәр күләмдә агач әзерли ала.

Агач бүлеп бирүгә нинди дә булса ташламалар каралмаган. Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе буенча агач бәясе Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитетының карары нигезендә исәпләнә.

Бу хезмәттән файдалану өчен шәхсән яки вәкил аша министрлыкка гариза һәм шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирергә кирәк.

Хезмәт күрсәтүдән баш тартуның иң еш сәбәбе мөрәҗәгать итүченең шәхси мәгълүматларын тулысынча яки агач сатып алу максатын дөрес күрсәтмәве тора.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

АВЫЛ ЯШЬЛӘРЕ НИЛӘР КҮРМИ

Районнарда, авылларда яшьләр ничек ял итә? Бу сорауга җавап эзләп, кулга каләм алырга «ВТ» газетасында оешкан «Туган тел» клубында әйтелгән фикер этәрде.

Алтын урталык эзләп

Теләче районындагы Баландыш авылы мәдәният йорты мөдире Илсаф Тимербаев салаларда яшьләрнең ял итү өчен мөмкинлекләре чикле дигән фикерен әйткән иде. Дискотекалар оештыруны чикләү, «комендант сәгате» дигән төшенчә бар. Бит дискотека яшьләрнең таныша, аралаша, ял итә торган урыны иде! Болын кадәр клубы булып та, анда шөгыль тапмагач, яшьләр кая барырга тиеш соң? Илсаф белән бу хакта аерым сөйләштек.

– Шәһәрдә яшьләр көн азагында ничек ял итәргә теләүгә карап, төрле урыннарны сайлый ала. Ә район һәм авылларда бердәнбер мөмкинлек – мәдәният йортына бару. Биредә дә алар өчен шартлар куанырлык түгел: бернечә өстәл уены, өстәл теннисы, кайбер авылларда бильярд бар. Әлбәттә, мәдәният хезмәткәрләре һәм китапханәчеләр яшьләрне җәлеп итү, ничек тә кызыксындыру максатыннан төрле чаралар оештырырга тырыша, ләкин заманча җиһазландырылмагач, бу көннәрдә ачу чаралары шәһәрдәге мөмкинлекләрне күреп ияләшкән яшьләрнең игътибарын тотып тора алмый, – диде Илсаф. – Күпчелек яшьләрне тотып торырдай чараларның берсе – проектордан кино карау, тик бу мөмкинлек тә, проектор булмау сәбәпле, барлык мәдәният йортларының да кулыннан килми.

> **Аның сүзләренчә, яшьләр өчен үтә торган чараларның тагын бер проблемасы – аларны оештыру белән өлкән яшьтәгеләрнең шөгыльләнүе. «Ике буын арасындагы фикерләү, «тренд»лар чагышмый», – ди ул.**

– Без яшүсмер вакытта авылларда дискотекалар гөрләп тора иде, рәхәтләнеп йөри идек. Әле бер көнне кызыксынып, архивларны карадым: дискотекалар төнге 2–3ләргә кадәр үткәрелгән икән ул чорда! – дип сөйләде Илсаф. – «Комендант сәгате» кышкы чорда – 22.00, җәен – 23.00гә кадәр. Чарада 18 яше тулмаганнар булса, без аларны кисәтәбез һәм өйләренә озатырга тырышабыз. Мәдәният йортында дискотека оештыру теләге булган очракта, алар планга «тематик кичә» буларак теркәлә. Яшьләр өчен зур чара оештырып, дискотека үткәрәм дисәң, моның өчен бернечә атна алдан хокук сакчыларына хәбәр ителергә һәм бәйрәм көнне полиция хезмәткәрләре саклап торырга тиеш. Тик әлеге мәрәҗәгать белән кергән очракта да ул әле рөхсәт ителә дигән сүз түгел. Мисал өчен, узган елны үзебезнең авылда Сабан туе мәйданыннан читтәрәк бию

selet.biz

Татарстанда барлыгы 1751 мәдәният йорты һәм клуб бар. Республикада 25 яшьләр үзәге эшли.

мәйданчыгы оештырып караган идек, ләкин хокук сакчылары кичке 10да музыканы туктатырга боерды. Җәен бу вакытта караңгы да төшми бит әле! Әлбәттә, без кулыбыздан килгәнчә, ике яктан да килешү эзләп, мондый чараларны төрле кысаларга кертеп оештырырга тырышабыз инде.

«Нишләргә соң?» дигән сорау туа. Илсаф Тимербаев әйтүенчә, яшьләрне тыңларга һәм тәкъдимнәрен ишетергә кирәк.

– Өстәмә матди ярдәм булган очракта бераз ниндидер үзгәрешләр кертеп булыр иде. Чөнки хәтта гади генә өстәл уеннары алу өчен дә мәдәният хезмәткәрләре үз акчаларын тотарга мәҗбүр кайчагында. Грантларда катнашыгыз, дияргә мөмкин, әлбәттә. Әмма бер мәдәният хезмәткәре барысына да ничек өлгерсен? – ди ул.

Хыялларга да биреләдек.
– Яшьләр өчен авыл һәм район җирендә заманча биналар, оешмалар, чаралар җитми. Мисал өчен, Казандагы Милли китапханәне алыйк: теләгән һәркем килеп, җаны теләгән эш белән шөгыльләнә. Район тирәсендә андый урын ачылса, бу искиткеч яңалык булыр иде. Гел көннәр ачып кына йөреп булмый бит. Мәдәният йортына әйләнеп кайтсак, шул ук заманча җиһазлау җитеп бетми, – ди мөдир.

Кадакка да басалар!

Арча мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе Ләйлә Хәкимова әйтүенчә, яшьләр өчен салаларда шартлар юк, дип әйтеп булмый. Мисалга үзләрендәге бер авылны китерде.

– Сикертән авылы күпфункцияле үзәгенә кичләрен яшьләр ашкынып киләләр. Хәтта Сабадан ук килүчеләр бар! – диде ул.

Яшь кеше буларак, яшьләрнең нәрсә көткәнен яхшы аңлый Ләйлә.

– Нейрографиядән алып, йога, кадакка басу, мехенди ясау, караоке кичәләре, велоярышлар, вальс дәресләре, «Ал кирәк, гөл кирәк» уеннары, кино көннәре, төрле мастер-класслар, чәйләрнең яңа төрләре белән танышу кичләренә кадәр була бездә. «Түгәрәк өстәл»ләргә аеруча игътибар бирәбез. Төрле көнкүреш вакыйгаларны, эчтәге шәхси проблемаларны, киләчәккә планнар, йөрәктәге хисләр, борчулар, намус, эгоизм, тугрылык турында сөйләшүләр алып барам. Яшьләр үз дөньяларына бикләнеп яши бүген. Психолог ролен башкарган чаклар да бик еш була, – ди әңгәмәдәш.

Клубның дискотекадан өзелгәне юк, ди. Дүшәмбедән кала, атна дәвамында уздыралар икән.

– Җомга, шимбә, якшәмбе мәдәният йортыбыз яшьләр шау-шуына күмелә, – ди Ләйлә. – Теләк булганда, мөмкинлекне тудырып була ул. Иң беренче чиратта, үзеңдә энергия ташып торырга тиеш. Шул вакытта тирә-юньдәге кешегә дә көнделсез булмас. Кызыклы чаралар мәдәният өлкәсе белән генә чикләнергә тиеш түгел.

Эшләп ял итү

Сер түгел: көнел ачуны кайгырту эшендә яшьләр белән бер дулкында булган кеше торса, үзеннән-үзе яшьләргә тартылу һәм аларны җәлеп итәргә тырышу булачак инде ул. Алдагы мисаллар да шуны күрсәтә.

Саба районындагы Явлаштау авылындагы клубка да әнә мөдир итеп институт тәмамлаган яшь кеше билгеләнгән. Чаралар да «яшәргән».

– Бездә дискотекалар уза, яшьләр дә чыга. Минем яшьтәгеләр дә, бездән яшьрәкләр дә йөри. Хәзер клуб күпләр өчен очрашып сөйләшү урынына әверелеп бара. Кайсылары бильярд уйный. Китапханәгә кереп чыгарга мөмкиннәр, – ди шушы авылда яшәүче Рәфидә Галимҗанова. – Мөдиребез – миннән бернечә яшькә кече кыз. Яшь кеше булгач, яшьләргә тартыласың инде ул. Шул сәбәплеме икән, авыл клубында яшьләрчә чаралар күбрәк уза башлады кебек. Моннан тыш төрле елларга багышланган дискотекалар уза (әйтик, 80–90 нчы еллар). Мин үзем хәзер китапханәгә генә чыгам.

Рәфидә әйтүенчә, авылда җәен – футбол, кышын хоккей ярышлары уза. Аларны салада яшәүчеләр, шул исәптән яшьләр дә бик көтеп ала икән.

– Ул – безнең өчен ял итү чарасы. Зурлап оештырыла да, – ди Рәфидә. – Әле күптән түгел генә башка район, авыллардан килеп, хоккей уйнап киттеләр. Спорт ягыннан зарланырлык түгел. Моннан тыш дини чаралар да яшьләрне җыйнау урыны булып тора. Авыл яшьләре эшләп ял итә, дип әйтер идем мин. Безнекеләр һәр эшне берләшеп эшләргә ярата. Безнең буын инде хәзер бәби чәйләре, өй туйларына йөрер вакытка җитте, шунда очрашып, ял итсәк кенә. Тимераякта шуарга чыгып керергә мөмкинбез.

– Атна азагын, клубка чыгу вакыты җиткәнен зарыгып көтеп ала идек. Дуслар, яшьтәшләр белән очрашу, дискотекаларга йөрү безнең чорда бик популяр нәрсә иде бит ул, – ди Балтачның Арбор авылы егете, «Мунча ташы» эстрада театры артисты Раннур Әүһәдиев. – Элек иске клубларга йөргәннәр, җырлаганнар, биегәннәр, нәрсәсен яшерәсең инде, сугышканнар да. Хәзерге клубларда биючесе дә, сугышучысы да юк. Клублар яңа, зур. Әмма кешенең кич чыгуларга мөнәсәбәте үзгәрде. Замана үзгәрде. Хәзер өйдә телевизор караучы да юк. Бөтен кеше – телефонда. Безнең күрше авылда – иске клуб. Һәр бәйрәм, һәр атна саен анда дискотека оештыралар.

Соңгы сүз урынына

Яшьләргә яшьләрчә булсын дип, мәдәният йортларын җитәкләгән өлкәннәрне эштән алып, аның урынына башка кеше куярга дигән сүз түгел әле бу. Проблема үзебездә дә.

Элек телефоны, интернеты булмагач, «йолдыз»лар да, башка кызыклар да уч төбендә түгел иде. Хәзер – барысы да күз уңында. Китап-газета укуны да телефонга алмаштырганны, концерт кую, концерт карау, чарада катнашуны да шул телефонда башкарып булганны…

Җиһазлау мәсьәләсе дә кискен тора. Элек кино карау халыкны ничек тупланган булса, хәзер дә кино күрсәтү нәтиҗәсен бирми калмас иде. Шәһәргә кинотеатрга бару бар кешенең дә хәленнән килми.

Замана шөгыльләреннән, замана белемнәреннән артта калмаска кирәк. Нишләп әле клубларда һаман да бәйләү, тегү, фольклорга гына урын бирелергә тиеш соң? Шул ук блогингка, монтаж, графика, IT белемнәргә, финанс грамоталылыгына өйрәтергә була бит. Махсус укытучы килгәнен көтәсе юк: бу эшне хәзер мәктәп яшендәгеләр дә яхшы белә.

Күп нәрсә яшьләрнең үзеннән дә тора. Теләк белдерү, оештыру, тәкъдим алардан да килергә тиеш. Тавыш бирмәсәң, кем ишетер соң?

ВИНЕРА ГАНИЕВА: «БУ ЮГАЛТУ КҮЗЕМНЕҢ НУРЫН АЛДЫ»

«Йолдыз чире»ннән иммунитет, вакыт сынавын узган җырлар, хәзерге эстрада уңышлары һәм кимчелекләре. Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Тукай премиясе лауреаты, бик күп җырчыларның остазы Винера ГАНИЕВА белән әнә шулар хакында сөйләштек. Җырчы тормыш юанычы, югалту һәм табышлары хакында да ачылып сөйләде.

:: Винера Ганиева дигәч, «Туй күлмәге», «Зәңгәр томан», «Зинһар өчен кермә төшләремә» дигән җырлар искә төшә. Хәзерге җырчыларда әнә шундый, җырчының визит карточкасы булырлык җырларга кытлык бугай. Моның сәбәбе нәрсәдә икән?

– Иҗатым бик нәтиҗәле булды дип әйтәсем килә. Бу җырларга «Бергә узыйк Казан урамын», «Сөембикә» дигән җырларны да өстәр идем әле. Шөкер, бүген дә иҗат белән яшим. Ә инде сәхнәгә аяк баскан мәлләрне искә алсак, беркайчан да «конъюнктурный» җырлар артыннан кумадым. Яраткан авторларым булды, гомер буе алар белән дус булдык, бергәләп иҗат иттек. Композитор Резедә Әхиярова, Рәшит Кәлимуллин, Луиза Батыр-Болгариның җырларын яратып башкардым. Сүз авторларына килсәк, Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин белән матур җырлар иҗат иттек. Рухлары шат, урыннары оҗмахта булсын. Хәзер без Наил Касыймов, Зөлфәт Хәким белән иҗади дуслар. Элек композитор, шагыйрь иҗат иткән җырны җырчы җырлый һәм аны худсовет тикшерә иде. Аның нәтиҗәсен өчәүләп зарыгып көтәбез. Бу – җырчыга да, авторларга да бик зур имтихан. Худсовет вәкилләре сүзен дә, сүзнең көйгә тәңгәллеген дә җиде кат иләк аша үткәреп тикшерә һәм башкару сыйфатына игътибар бирә. Мөгаен, шуңа ул вакытта чын мәгънәсендә камил җырлар туа алгандыр. Сез телгә алган җырлар алар бит – вакыт сынавын узган шедеврлар. Аларны өч кеше иҗат иткән, кирәк чакта төзәткән, камилләштергән. Хәзер менә шушы эш юк.

> Минем тәнкыйтьлисем дә килми, ләкин җиңел юл сайлап, тамашачыны да җиңел көйгә, такмакка ияләштереп бетерделәр инде. Җитди җырларга кытлык торган саен үзен ныграк сиздерә. Җыр бит әле ул биетергә генә түгел, уйландырырга, моңландырырга, елатырга да тиеш. Җыр белән тәэсир итү турында да онытып барабыз кебек.

:: Композитор Резедә Әхиярова белән иҗади дуслык ничек башланды? Ул вакытта җырчыга җырларны сатып алырга кирәк идеме?

– Минем җыр сатып алганым булмады. Җыр сәнгатенә тиз генә килмәдем. Эстрадага килгәндә, мин инде опера театры солисткасы буларак формалашкан һәм «Татарстанның, Россиянең халык артисты», «Тукай премиясе лауреаты» дигән дәрәҗәле исемнәр алган идем. Аңа башка зур бүләкләр дә кушылды. Авторлар исә үзләре мине сайлыйлар иде. Шуңа җырны сату турында сүз бармады. Хәзер исә яшьләр сүзен дә, көен дә сатып ала, аранжировка, ротация өчен дә түли. Бер яктан, бу дөрестер. Җыр авторлары хезмәте акча белән бәяләнергә тиештер. Җырчы да бит хәзер бушка җырламый, чыгышы өчен түләү ала. Шуңа күрә авторлардан иҗат җимешен сатып алу аклана. Ә авторлык хокукларын яклаучы оешмаларның җырны «ике тиен» белән бәяләве бик үк дөрес түгел.

Резедә Әхиярова белән дуслыкка инде кырык елдан артык. Әле дә хәтердә: тәүге мәртәбә радиода очраштык. Ул чакта Камил радиода тавыш операторы булып эшли иде. Мөнирә Хәбибуллина белән классик әсәрләр яздырганда, Резедә минем тавышны ишеткән һәм җыр тәкъдим итеп карарга булган. Шулай бер-бер артлы бик матур җырлар туды. Менә шулай операда да, эстрадада да эшли башладым. Резедә Әхиярова «Шагыйрь мәхәббәте» операсында (либретто авторы – Ренат Харис) Зәйтүнә партиясен минем тавышны күздә тотып иҗат итте. Бу спектакльне эшләү дәверендә без өчәү бик күп аралаштык, бергәләп эшләдек. Шуңа күрә татар операсын язуның никадәр четерекле һәм авыр булуын кулны йөрәгемә куеп әйтә алам. Резедәгә бу җәһәттән мин бик рәхмәтле. Бу операдан соң да без бик күп җырлар иҗат иттек. Ул минем рухи дөньямны баетты, иҗатташым һәм рухташым булды.

:: Бердән, эстрада белән операны бердәй тигез алып бару җиңел булмагандыр. Икенчедән, Виолетта, Джильда, Микаэла, Сәрвәр, Зәйтүнә кебек саллы рольләрдән соң, ничек «йолдыз чире» белән чирләмәскә?

– Андый чир белән чирләмәдем. Беркайчан да бер кешедән дә көнләшмәдем. Бишенче курста укыганда ук, опера театрының стажерлар төркеменә кабул итәләр. Әлбәттә, яшь артистка кырын күз ташлаучылар да булгалады. Аңа игътибар итмәдем, эшләдем дә эшләдем. Яңа образлар тудыру өчен эзләндем, өйрәндем, үз профессиямнең фанатына әйләндем.

Бишенче курста профессияләр ярминкәсендә катнашу мөмкинлеге була. Безне Красноярск шәһәренә алып бардылар. Ул чакта Дмитрий Хворостовскийның да безнең белән ярминкәдә җырлаганы хәтердә. Мин анда Россининың Розина каватинасын башкардым. Шуннан соң берничә театр эшкә чакырды, Казан опера театры баш дирижеры исә: «Сине беркая да бирмибез», – диде. Шулай итеп катлаулы да, кызыклы да иҗат юлы башланды. «Риголетто» операсын карарга Камал театры режиссеры Марсель Сәлимҗанов килгән булган, ролемне бик яраткан, сәхнә артына кереп мактавы минем өчен зур дәрәҗә булды. Менә шунда ул мине Камал театрына «Зәңгәр шәл»дә уйнарга чакырды. Шулай итеп җиде сезон Мәйсәрә ролен башкардым. Шуларны искә төшерәм дә: «Могҗиза булган бит бу», – дип куям. Нинди юл үтелгән, нинди артистлар белән аралашканмын! Мин күзәтергә, нинди артист белән эшләсәм дә, аннан нәрсә дә булса өйрәнергә тырыша идем. Үземнең хезмәттәшләрем уйнаган премьераларны да карап бардым. Лариса Башкирова, Зилә Сөнгатуллина, Алла Фадеечева, Хәйдәр Бигичев, Руслан Дәминов – барысына да игътибар итәргә, актерлык алымнарын күзәтеп барырга тырыштым.

:: Мәдәният институтында «урак өсте» – сессияләр вакыты. Институтта татар җырчыларын әзерләү ничек бара? Нинди җырчылар килә, татар телен беләләрме?

– Хәзерге вакытта институтта чын мәгънәсендә «урак өсте». Безнең кафедра укытуны берничә юнәлештә алып бара. Быел без беренче курска 40 студент кабул иттек. Әлбәттә, алар төрле юнәлешләрне сайладылар. Безгә укырга бөтен Россиядән, чит илләрдән дә киләләр һәм бик зур кызыксыну белән укыйлар. Бирдә татарлар гына түгел, төрле милләт вәкилләре бар. Кытай, Үзбәкстан, Казахстан, Таҗикстаннан һәм башка ил, республикалардан килеп укыйлар икән, бу – уку йортына кызыксыну зур дигән сүз. Чит ил кешеләре белән тәрҗемәче аша аралашырга туры килә. Хәер, эмпирик алымны да кулланабыз. Музыкада аңлашмыйча калу мөмкин түгел. Шул ук вакытта укытучыдан бик зур тоемлау да таләп ителә. Һәркайсының тавышы уникаль. Аны бозмаска, диапазонын үстерергә, тембрын матурларга ярдәм итәргә кирәк. Бу – бик зур җаваплылык. Аннан килеп, бездән җырчы дипломы гына алып чыкмыйлар. Алар – педагоглар да. Бу бик зур бурыч йөкли. Һәм мин, телевизорны ачып, һәр икенче җырчының безнең шәкерт икәнен күреп, аның планканы төшермәвенә инанып, бик шатланам. Шул ук вакытта бик күп җырчыларның фразаларны дөрес кулланмавы, басымны дөрес куймавы көендерә дә. «Их, укырга килсеннәр иде, өйрәтер идем», – дип куям. Укырга, камилләшергә, эшләргә кирәк. Хезмәт белән генә ниндидер нәтиҗәгә ирешеп була. Табигатьтән килгән сәләтем бар, тавышым бар дип, ялкаулыкка бирелсәң, булганны да югалтуың ихтимал. Сәләтне белем нигезенә утыртырга, үзеңне гел камилләштерергә кирәк.

:: Татарча белмәсәм дә ярый, дигән татар эстрадасы җырчысына ни әйтер идегез?

– Эчемне пошыра торган берничә җырчы бар. Болар – руслар, ләкин сүзләрне вата-җимерә татарча җырлыйлар. Күрәсең, ачыш ясыйм дип уйлыйлардыр инде. Әлбәттә, аларның спонсорлары барлыгы билгеле. Җырны да бик шомартып, бик чистартып яздыралар. Мөгаен, алар рус эстрадасында уңыш елмаймаячагын аңлый, шуңа татар эстрадасында үзләрен сынап карарга теләгәннәрдер. Тик бит тавыш мөмкинлеге ташка үлчим генә. Белмим инде, башка сәнгатькә аяк баскансың икән, татарча дәресләр алырга, җырлау манерасын татарчалаштырырга да кирәктер. Безнең Европа дәрәҗәсендәге җырчылар бар. Алинә Шәрипҗанова, Илнар Миранов, Эльза Исламова, мәсәлән, алар тагын да бар инде. Менә андый җырчыларның чыгышы йөрәккә май булып ята. Шулар янында акырып булса да алдырырга тырышканнары да бар. Аларын чын күңелдән кызганам. Чөнки тавышның яңгыраш вакыты чикле, ул 15–20 ел гына сыйфатлы була. Беркем дә яшь килеш калмый. Тән дә, тавыш та үзгәрә. Менә минем дә тавышым түбән регистрга күчте. Ләкин опера театрында эшләү нәтиҗәсендә, профессиональ нигезе булганга, тембр үзгәрмәде.

:: Татар эстрадасына нинди бәя бирер идегез?

– Кызганыч, ул төрле сыйфатта. Яхшылары бар, урталыклары. Әмма минем эстраданы начар дип әйтәсем килми. Һәвәскәрнең дә сәхнәгә чыгасы килә. Җыр бит

ул – һәр кешенең юлдашы. Җырга мәхәббәт кешене үзен күрсәтергә этәрә дә инде. Гәрчә шул юнәлештә белем алмаса да. Әмма сәхнәгә чыккансың икән, шул юнәлештә белем алырга кирәк. Һич югы тавышыңны үстерү өчен булса да. Ә һәвәскәр җырчы икән, бәлкем, аның сәхнәсе дә аерым булырга тиештер.

:: Сезне, укучыларыгызга артык зур игътибар бирә, диләр. Моңа ачуыгыз чыкмыймы?

– Ничек инде үз шәкертләреңне, үз укучыларыңны яратмыйсың?! Мин бит алар белән иң зур байлыгым – тәҗрибәм белән бүлешәм. Мин 50 елдан артык сәнгать өлкәсендә. Башта бары тик опера җырчысы булырга хыялландым. Бу җәһәттән остазларым бик зур үрнәк булдылар. Бу – училищеда Клавдия Захаровна Щербинина, консерваториядә Валентина Андреевна Лазько, Нияз Курамшевич Даутов. Алардан җырчы һәм остаз булуның барлык сыйфатларын сеңдердем. Мин бөтен тәҗрибәм белән бүлешергә әзер, шәкертләремне бик яратам. Алардан килгән энергетика исә миңа яшәргә көч бирә. Көннең узганын сизмим дә.

:: Үзегезгә ошаган проект нинди, аның уңышы һәм кимчелеге нидә?

– Шәхсән миңа «Үзгәреш җиле» проекты бик кадерле булды. Минем юбилей вакытында Рөстәм Миңнеханов: «Эстраданы дөнья дәрәҗәсенә күтәрү өчен нәрсә эшләргә кирәк?» – дигән сорау бирде. Шуннан «Үзгәреш җиле» барлыкка килде. Анда мин җырлар сайладым, башкаручылар кастинг узды. Беренче елларда «Голос» проекты аранжировщиклары белән эшләдек. Бәлкем, аларның безнең җырларны, башкару үзенчәлекләрен, тамашачыны да бик үк аңлап бетермәүләре нәтиҗәсендәдер, проект тәнкыйтьләнде. «Үзгәреш җиле» инде 9 мәртәбә үтте. Ул елдан-ел камилләшә барды. Мондый проект Россиядә дә бердәнбердер әле. Бу проект балалар өчен «Үзгәреш җиле» проектын тудырды. «Сәйлән» фестивале җиңүчеләренә «Үзгәреш җиле» оркестровкасына кушылып җырларга мөмкинлек бирелде. Нәтиҗәдә балалар гомумән икенче яктан ачылдылар. Бу – шулай ук бик зур казаныш.

:: Чакырсалар, нинди рольдә уйнар идегез?

– Мин әле дә Резедә Әхиярованың Ренат Харис либреттосына язылган «Сөембикә» операсында бала караучы ролен бик яратып башкарам. Сәхнәгә берничә минутка гына чыгып керү минем өчен сулар һава кебек кирәк. Ул – энергия чыганагы.

:: Тормышыгызда югалтулар да булды. Вакыт дәвалый, диләр, бу чынлап та шулаймы?

– Әйе, вакыт дәвалый диләр, ләкин мин әлегә алай дип әйтә алмыйм. Камилне бик юксынам, бик сагынам. Ул башымнан бер генә секундка да чыкмый. Институтта гына бераз онытылып торам. Шуңа күрә минем өчен төп дәва – эш. Камилемне театрда да, радиода да бик сагыналар. Ул бит Опера театрында тавыш режиссеры иде. Алыштыргысыз кешеләр юк, диләр. Бар икән. Камилне алмаштыручы кеше театрда әле дә юк. Камилдәй атмосфера тудыра алучы юк. Аның ишетү, тоемлау сәләте искиткеч иде. Без аның белән эшкә бергә бара, бергә кайта идек. Бик рәхәт чаклар булган. Минем өчен бу – әйтеп бетергесез югалту. Аны аңлатып та булмый. Кайгыңны уртаклашам, дип шалтыратучылар күп булды, мин ул сүзләрне ишетми идем. Кайгыны уртаклашып булмый. Аны үзе кичергәннәр генә аңлый. Андыйлар да бик күп. 37 ел кадердә, хөрмәттә яшәгәч, югалту бик авыр. Ул – минем зур мәхәббәтем. Мин бүген дә мәхәббәтебезгә тугры. Мин аңа шушы мәхәббәтем өчен бик рәхмәтле.

> Менә шушы өч елда күзләремнең нуры югалды... Анда хәзер сагыш, югалту, хәсрәт. Элеккеге язмаларда минем нинди бәхетле хатын булуым күренә. Шуларны карап юанам. Шул чакларны өзелеп сагынам.

:: Хәзер тормышыгызда юанычыгыз һәм таянычыгыз кем?

– Әлбәттә, туганнарым, шәкертләрем. Эшкә Әсхәт энем йөртә. Күршедә генә гаиләсе белән Фәрит энем яши. Нишлисең, тормыш дәвам итә.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

__Айзирәк ГӘРӘЕВА-АКЧУРА__ Төркиядә яшәп иҗат итә. Мөһаҗирләрнең чит илләрдә үткән гыйбрәтле тормышын өйрәнә һәм моңарчы җәмәгатьчелеккә киң таралмаган читтә яшәүче татарларга кагылышлы мәгълүматларны туплый. 2021 елда Татарстан китап нәшриятында «Ипекәй» дип аталган китабы басылып чыкты. Әлеге хикәя «Казан утлары» журналының Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү комиссиясе ярдәмендә үткәрелгән бәйгедә «Хикәя» номинациясендә җиңү яулады.

АЙЗИРӘК ГӘРӘЕВА-АКЧУРА (ХИКӘЯ)

КУЕНЫҢДА НИ БАР?

Дөнья аларны куарга керешкәнне белгәнгәме, һәр көнне, һәр мизгелне мөмкин кадәр тәмләп сузмакчылар. Әнә шәһәр мәчетеннән җомга намазы бетәр-бетмәс яшьрәкләр урамга ташланды, ә картлар мәчет чәйханәсеннән күләгәлерәк урын бардады. Аннары, җәмигътән каядыр ашыгып китүчеләргә: «Барыгыз, барыгыз, тизрәк булыгыз! Куыгыз дөньясын! Тоттырыр микән! Анысын инде безнең яшькә җиткәч белерсез», – дигән төсле, хикмәтле генә карап калдылар. Көн кызуыннан бераз зарланышып алгандай итсәләр дә, кояш астында чәй ташып, карачутырга әйләнгән җитез чәйче малайның подноска берьюлы 10–15 филҗан – нечкә билле төрек стаканы – чәй тезеп китергәнен сабыр көттеләр. Килгәч, бәләкәй-бәләкәй йотымнар белән, әкрен генә эчтеләр. Дөньясы ашыкмасын әле куарга...

Мәчет юлга терәлеп диярлек торганга күрә, алгы якта ачык һавада чәй эчәрлек кулай, иркен урын калмаган, шуңа күрә чәйханә, тәһарәтханә ян тарафтарак урнашкан. Шунда ук, бераз мәчет артына табарак китсәң, җеназахәнә бар. Аулаграк урын булгангамы, җеназаханәнең бердәнбер тәрәзәсе өстендә, дивар почмагында кошлар остасы карлыгач тырышып та куйган: чыбык-чабык ташып оя үргән, нык торсынга балчык белән сылаган. Тәрәзәдә исә скотч белән ябыштырылган кәгазьдә кояшта уңа башлаган язу күренә: «Карлыгач оя корган, тәрәзәне ачмагыз». Җилдән җитез бу кошларның ихатага оя коруын бәхет китергәнгә юраган төрекләр өчен болай язып торуның бер кирәге дә юк кебек инде. Алай да кисәтү – саклык билгесе. Шунысы да бар бит әле: карлыгач оясын ялгыш кына да туздырырга ярамый, югыйсә үзең өйсез калырсың, диләр. Астан караганда чыннаяк төсле балчык оядан кагылгысыз кошның ак түше күренеп-күренеп ала, аратирә каядыр очып-урап килә. «Үз оямда – үз көем», – дип яшәү шулайрак була, күрәсең.

Җитмешне узган, тәбәнәк һәм җиңел гәүдәле Мөнир карт һәр атнада җомгага шушы, олы юл өстендәге яшел төстәге мәчеткә акрын гына атлап килә. Әллә ни ерак яшәми. Аның тере җаннардан аерылмаган, әмма рухларга якын торган үзгә халәте салмак йөрешеннән үк сизелеп тора. Мәчет дивары буйлап биеккә үрмәләп үскән йөзем агачы төбендә чәй эчеп утырырга бер татар очратса, Аллаһыдан килеп ирешкән җомга бүләгедәй итеп кабул итә. Төрекләр әйткәнчә, йөзем йөземгә карый-карый карала, ә татар картлары чәй эчәэчә җанлана. Элек-электән мөһаҗир татарлар шәһәрнең бу тирәләрендә шактый яшәгәнгә, җомга намазына байтак тупла期налар иде. Ләкин ул су кебек агып киткән елларда алар да дөнья куа иде шул: кырык кат тир түгә-түгә корып җибәргән күн эшкәрту, зәркәнчелек кебек остаханәләренә, гомер итәрлек ризык биргән кибетләренә, күбесе, әлбәттә, авылдан чыкканнарны шәһәрләштергән шикәр заводына йөгерә иде.

Ә хәзер... Ике-өче килсә, рәхмәт укырсың. Аннары шәһәрдә мәчет җитәрлек, һәркем үз өенә якынракка бара. Мөнир карт көтә дип, бирегә йөрсеннәрме?! Бу мәчет ачылганга җитмеш елдан артык, ул җитмеш елда татарларның кайсы кая китеп бетмәгән инде... Фани дөньядан бакыйлыкка күченгәннәре никадәр! Адәм баласы олыгаю, искерү, үлү кебек сыйфатлардан хали түгел. Беркемнең әлегә кадәр мәңге яшәтә торган әбелхәят чишмәсеннән суны кушучлап, чөмереп эчкәне юк, хәтта ярты тамчысын йотканы юк.

Кайчак шәһәрнең тар урамнарын махсус урап йөри. Вай-вай... Балчык, таштан салынган, акбур белән агартылган бакчалы өйләр, кая югалып беттегез?! Берәм-берәм иштеләр, урыннарына бишәр, хәтта олы юл читләрендә җидешәр катлы йортлар калыкты. Гөрләп үскән бакчалар юкка чыкты, тирә-як таш булды. Шәһәрдә һәр апартманның – подъездның – үз исеме. Аларны укып барганда таныш татарча атамалар очрата, хуҗаларын чакырып чыгарырдай җилкенә. Җаек, Идел, Сакмар, Урал... Кайчандыр, димәк, биредә татарлар яшәгән, апартманнар аларның мөһаҗирлектә алган яңа фамилияләрен менә шулай саклый.

...30–35 яшьләрдәге, җыйнак кына сакал җибәргән, кыска чәчле, бераз кысык күзле, аксыл тәнле, озынрак, ябык кына бер мосафир кулындагы чәен Мөнир карт утырган агач өстәлгә куйды. Арка букчасыннан планшетын чыгарды. Шуннан соң бераз читтәрәк торган урындыкны өстәл янына этеп утырды.

– Әссәламегаләйкем, – дип, ябык гәүдәдән һич көтелмәгән калын, гөрелдәп торган тавыш белән сәлам бирде. Һәм җавап көтми планшетыннан нидер карый башлады.

Уйларындагы татар чордашларыннан аерыла алмый торган карт бераз сәерсенеп китте. Каршында ата-бабалары яшьлеген хәтерләткән, моңа кадәр биредә бөтенләй очратмаган мосафир утыра иде.

– Вәгаләйкемәссәлам, – дип җавап биргәч үк: – Кайсы мәмләкәттән килдең? Казаннанмы? – дип, татарча сорашыра кереште.

Бүгенге Русия татарларының никадәр аз сүзле икәнен, сөйләшкәндә сорауларга җавап биреп торуны, гадәттә, кирәксенмәүләрен, аралашуга әллә ни атлыгып тормауларын һәм күбрәк русча сөйләшүләрен каян чамалап бетерсен, җавап көтте. Мосафир хәтта, чит илдә тора салып, татарча сорау бирелгәнгә аптыравын йөзенә чыгармады, бары тик карт җавап көтеп карап торганга «әйе» дигәндәй баш какты.

Чынлыкта бит бик кызык иде. Чит илдә гомереңдә беренче мәртәбә күргән кеше синең татар икәнеңне аңлап алсын, җитмәсә, татарча эндәшсен әле... Бу арада мосафирның чит илдә татар телен ишетүенә инана алмаган баш мие күзәнәкләре ут капкандай төрлесе төрле якка чабышты. Мөселманлыкта шәкерт булып йөргән күңелендә буыннардан буыннарга мөгаллимлек иткән ил тәрбиясенең киеренкелеге сизелде. Ә бәлки, каушады гына?! Юк, аның бары төзелеш сыйфаты, хассияте үзгә. Русча сөйләшкән туристлардан биш метр ераклыкта йөрсә дә, әле генә төрек мәчетендә намаз бетүгә эченнән догаларын, теләкләрен русча укып утырган татарлардан иде ул. Өстәвенә ярымцифрлашканнардан.

Ә Мөнир карт беркая ашыкмады. Мәмләкәттән – ата-бабалары җиреннән килгән мосафир белән очраштырган Раббысына, тавыш-тынсыз, бары иреннәрен сизелер-сизелмәс кенә кымшаткалап, ярты сәгатькә якын шөкрана кылып утырды. Шушы шөкрана тулы мизгелдә бер карт кына түгел, аның белән бергә оясыннан ара-тирә башын чыгарып-чыгарып тирә-юньне күзәткән карлыгач, чәйханәне тышкы дөньядан аерып торган таш диварга тезелгән аксыл-коңгырт күгәрченнәр, ара-тирә «үзгәреш бармы» дигәндәй чырык-чырык килеп очкан чыпчыклар, хәтта 70 еллык мәчет мосафирның сөйләшүен көтте төсле. Төймә күзле бер күгәрчен, түземлеге төкәнде, өстәлләренә үк килеп кунды. Муенын боргалап, ялт-йөлт каравыннан ук барысы да аңлашылды. Җитәр, сөйләш! Бер тавыш-тын чыгар!

Дәвамы бар >

КОТЛЫЙБЫЗ!

Яшел Үзән районының Бакырчы авылында туып, бүген Сургут шәһәрендә яшәүче авылдашыбыз

Әлфия Рухулла кызы БӘХТИЯРОВАны юбилее белән ихластан тәбрик итәбез.

Әлфия Рухулловна, сез үз эшегезне зур осталык белән башкаручы, тынгысыз, киң күңелле, авылдашларыбыз арасында зур ихтирам казанган ханым. Авылыбыз өчен җан атып, аның яшәеше өчен борчылып, һәрдаим булышып, зур эшләр башкарасыз. Без сезне матур юбилеегыз белән котлап, иң изге теләкләр юллыйбыз. Сезгә нык сәламәтлек, күңел күтәренкелеге, бары тик күңелле вакыйгалар, бәхет, бәрәкәтле тормыш телибез. Гел шулай гади һәм кешелекле, олы җанлы булып калыгыз. Якыннарыгызның кадер-хөрмәтен тоеп, озак еллар яшәргә язсын.

Сабыр да син, гади, кешелекле,
Кылган эшең – бары изгелек.
Шатлыкларда үтсен синең көннәр,
Бәхетләрең булсын гомерлек.
Юбилееңда изге, матур хисләр
Күңелеңдә калсын уелып.
Тәбриклибез сине чын күңелдән,
Барыбыз да бергә кушылып.

Зур хөрмәт белән, Бакырчыларың

Беләсең килсә...

1 Durak сүзе төрекчәдән ничек тәрҗемә ителә?
а) ак юл;
б) тукталыш;
в) акылсыз.

2 Кайбер зоопаркларда мондый хезмәткәр бар:
а) крокодил стоматологы;
б) пандалар кочаклаучы;
в) фил борынын кашучы.

3 Моның кайсы материк түгел?
а) Арктика;
б) Антарктида;
в) Австралия.

4 «Пи» саны:
а) 3,1415355926;
б) 3,1415653592;
в) 3,1415926535.

Җаваплар: 1. б); 2. б); 3. а); 4. в).

... -китем
Күңел ачу ТВ-каналы
Дөя
Мәйдан берәмлеге
Йозак «бабасы»
...-тирә
Ризык
АКШ илендә 50
Уеннан чыккан нәрсә
Бабай хәләле
Завод «ресторaны»
Латыйпова
Фильтр
Геометрия туганы
К-700, ДТ-75, МТЗ-80
Күңел ургылуы
... тәңкә
Зур ярымутрау
Кызыгу
Иң зур уен коралы
Әкияти яшелчә
Аспирин
... Юзиев
Соңгы
... Гранде
Линзалы ТВ-җайланма
Курәчәк
Җеп түгел
Фәнни хатын
Газета
Рус исеме
Авыз эчендә
Каралты
Абдулла ...
Күтәргеч
Феррум
Бала ... балдан татлы
Башка урында булу дәлиле
Гана, Мисыр, Канада, Кытай
Пот
Япон токмачы
Базарлы Матак
Алтунян
Табанаков
Сугыш җәрәхәте
Нота
Абый-...
Кытай илбашы
Тимершәех
Тотнак
Әле чишәсез
Кисәкчә
Өнгә килү
Апрель
Җәһәт
...-буран-нар
Башкорт районы
Долларның рус туганы
Татар ир-ат исеме
Аромат
Кукмара киеме
Кече Сәгъдәтшин
һәм, белән
«..., йөрәгем, су бирегез»
Рекламалы газ
Физик, Нобель лауреаты
Нота
Рэпер Канье Уэст
...-талашмый яшәгез
Электрон документ
РФ республикасы

Сканворд җаваплары

Горизонталь: ТНТ, келә, ар, ара, уймак, штат, Динә, орган, шалкан, бакыр, Нил, язмыш, аңкау, галимә, МК, тимер, баласы, Әлки, алиби, ил, сын, Аршак, яра, уяну, апа, сканворд, ансат, неон, ис, итек, Нияз, Раил, уф, әрләшми, файл, Карелия.

Вертикаль: ашханә, лапас, иләк, кран, Алиш, Си, дару, Азат, Акчурин, так, терәк, Наил, кар, фа, үлем, әби, Миякә, Илдар, аш, алгебра, илә, Йе, актык, Ариана, Шалл, нар, сум, трактор, ибикон, Фирая, Ямал, ре, Гүзәл, удон, Ася, ни, ымсыну, ашкыну, яз.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән. Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 11230 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 209

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+